ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.06.2018 Казан ш. № 174

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 19 июнендәге 147 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы табигый монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны башкаручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлеше өлешендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 19 июнендәге 147 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт тарафыннан җайга салына торган

бәяләр (тарифлар) өлкәсендә газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы табигый монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны башкаручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлеше өлешендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына, аны тәкъдим ителгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
2017 елның 19 июнендәге 147 номерлы
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
2018 елның 9 июнендәге 174 номерлы
боерыгы редакциясендә)

# Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы табигый монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны башкаручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлеше өлешендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламенты

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕНЕҢ АТАМАСЫ

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы табигый монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны башкаручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлеше өлешендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламенты (алга таба - Регламент) дәүләт функциясен башкарганда Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының административ процедураларының, административ гамәлләренең срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

Дәүләт функциясенең атамасы: «Җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы табигый монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, каты коммуналь

калдыклар белән эш итү буенча региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны башкаручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлеше өлешендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру (алга таба тиешенчә - дәүләт функциясе, төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)».

1.2. Дәүләт функциясен башкаручы – Дәүләт комитеты.

Дәүләт функциясен турыдан-туры башкаручылар - Дәүләт комитетының структур бүлекчәләре, алар турындагы нигезләмәләрдә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру каралган булырга тиеш.

Дәүләт комитеты дәүләт функциясен башкарганда Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары (алга таба - прокуратура органнары), экспертлар, экспертиза оешмалары, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, үз-үзен җайга салучы оешмалар, юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар белән үзара хезмәттәшлек итә.

«Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба - тикшерүләрнең бердәм реестры) тиешле мәгълүмат кертүне Дәүләт комитеты вәкаләт биргән вазыйфаи зат башкара.

-

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН БАШКАРУНЫ ҖАЙГА САЛА ТОРГАН НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1.3. Дәүләт функциясе Дәүләт комитеты тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба - КоАП РФ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2002, № 1, ст.1, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Табигый монополияләр турында» 1995 елның 17 августындагы 147-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 147-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1995, № 34, ст. 3426, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 89-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1998, № 26, ст. 3009, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗномерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1999, № 14, ст. 1667, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 35-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2003, № 13, ст. 1177, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 19, ст. 2060, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2008, № 52, ст. 6249, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 190-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010, № 31, ст. 4159, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗномерлы Федераль закон (алга таба – 416-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, № 50, ст. 7358, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясенең күмәрләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын раслау турында» 2004 елның 21 гыйнварындагы 24 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 21 гыйнварындагы 24 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2004, № 4, ст. 282, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимиятенең тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә органнарының табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуны һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыруда катнашуы турында» 2008 елның 10 декабрендәге 950 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2008, № 50, ст. 5971);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга план буенча тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010, № 28, ст. 3706, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 28 сентябрендәге 764 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010, № 40, ст. 5090, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торбаүткәргечләр аша газ куу хезмәтләрен күрсәтүче табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат

ачу стандартлары турында» 2010 елның 29 октябрендәге 872 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 29 октябрендәге 872 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010, № 45, ст. 5855, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары турында» 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2013, № 205, ст. 205, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм кайберләренең үз көчләрен югалтуларын тану хакында» 2013 елның 27 июнендәге 543 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2013, № 27, ст. 3602, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары һәм җайга салучы органнар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартлары турында» 2013 елның 5 июлендәге 570 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 июлендәге 570 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2013, № 28, ст. 3835, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын булдыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2015, № 19, ст. 2825, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларын раслау турында» 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2016, № 26, ст. 4068);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамавы турында искәртүне төзү һәм юллау, мондый искәртүгә юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан ризасызлыклар белдерү һәм аларны карау, мондый искәртүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы , (www.pravo.gov.ru), 2017, 14 февраль, бастыру номеры 0001201702140002);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырылганда һәм үткәрелгәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан тиешле документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан йә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә,

документлар һәм (яки) мәгълүмат соратып алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2016, № 25 апрель, № 17, ст. 2418);

Тикшерүләр оештырылганда һәм үткәрелгәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан тиешле документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан йә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында түләүсез нигездә соратып алына торган документлар һәм (яки) мәгълүмат исемлеген раслау турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы күрсәтмәсе (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы күрсәтмәсе) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2016, № 18, ст. 2647, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Табигый монополияләр субъектлары булып торган электр энергиясе һәм куәте базарлары субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу формаларын раслау турында» 2014 елның 24 октябрендәге 1831-э номерлы боерыгы (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы , (www.pravo.gov.ru), 2015, 15 гыйнвар, бастыру номеры 0001201501150004);

Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Торбаүткәргечләр аша газ куу хезмәтләрен күрсәтүче табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу формаларын, срокларын һәм ешлыгын, шулай ук күрсәтелгән формаларны тутыру кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 31 гыйнварындагы 36-э номерлы боерыгы (Российская газета, 2011, 6 апрель);

Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Мәгълүматны «Интернет» челтәрендә бастыру юлы белән ачу һәм мәгълүматны «Интернет» челтәрендә бастыру юлы белән ачканда Россия Федерациясе башкарма хакимиятенең тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендәге органнарның (су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны раслау буенча вәкаләтләр Россия Федерациясе субъекты законы белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган очракта җирлекнең яки шәһәр округының җирле үзидарә органнары) җайга салына торган оешмалар белән үзара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2014 елның 16 декабрендәге 2244-э номерлы боерыгы (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы, (www.pravo.gov.ru), 2015, 6 апрель, бастыру номеры 0001201504060024);

Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Мәгълүмат ачу стандартларының үтәлешен системалы рәвештә күзәтү һәм аңа анализ ясау турында хисапның һәм электр энергетикасы өлкәсендә һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләргә (тарифларга) керә торган инвестиция ресурсларыннан файдалануны системалы рәвештә күзәтү һәм аңа анализ ясау турында хисапның формаларын раслау турында» 2014 елның 20 февралендәге 201-э номерлы боерыгы (алга таба - 201-э номерлы боерык (Российская газета, 2014, 4 июнь);

Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Ачылырга тиешле мәгълүматның кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар һәм тарифларны җайга салучы органнар тарафыннан тапшырылу формаларын, шулай ук мондый формаларны Тутыру кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 19 июнендәге 792/17 номерлы боерыгы (алга таба – Россия ФАСның 2017 елның 19 июнендәге 792/17 номерлы боерыгы (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы, (www.pravo.gov.ru), 2017, 14 сентябрь, бастыру номеры 0001201709140005);

Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары тарафыннан мәгълүмат ачуның бердәм формаларын раслау турында» 2017 елның 14 июлендәге 930/17 номерлы боерыгы (алга таба – Россия ФАСның 2017 елның 14 июлендәге 930/17 номерлы боерыгы (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы, (www.pravo.gov.ru), 2017, 10 август, бастыру номеры 0001201708100039);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба - Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10, ст. 1214, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 5 августындагы 555 номерлы карары (алга таба – ТР МК 555 номерлы карары) («Татарстан Республикасы законнар җыелмасы», 11.08.2017, № 60, ст. 2211);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 нче карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 29, ст. 1195, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ) ОБЪЕКТЛАРЫ

1.4. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектларын җайга салына торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы түбәндәге юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның (алга таба – юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар) эшчәнлеге тәшкил итә:

1) Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ куу өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы табигый монополияләр субъектлары;

2) электр энергиясен күмәрләп сату базары субъектлары (Россия Федерациясе субъектының җайга салучы органы компетенциясенә караган өлешендә);

3) электр энергиясен ваклап сату базары субъектлары;

4) җылылык белән тәэмин итүче оешмалар;

5) җылылык челтәрләре оешмалары;

6) каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ операторлар;

7) каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторлар;

8) кайнар су белән тәэмин итүче оешмалар;

9) салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суны чыгаручы оешмалар.

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ) ПРЕДМЕТЫ

1.5. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметын юридик затлар, индивидуаль эшкуарларның җайга салына торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру барышында мәгълүмат ачу стандартларын үтәү өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсенә караган мәҗбүри таләпләрнең (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәлүе тәшкил итә, аерым алганда:

1) мәгълүмат ачу факты;

2) мәгълүмат басылып чыгу чыганагы;

3) мәгълүмат ачу сроклары һәм ешлыгы;

4) мәгълүмат ачуның тулылыгы;

5) мәгълүмат басылып чыгу чыганаклары турында Дәүләт комитетына хәбәр итү тәртибе;

6) мәгълүмат тапшыру формалары һәм билгеләнгән тәртиптә расланган бу формаларны тутыру кагыйдәләренең үтәлүе;

7) ачылган мәгълүматның дөреслеге;

8) юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның товарларын кулланучыларның һәм хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның язмача соратулары буенча, шул исәптән язмача соратуларны теркәү, аларны карауның үз вакытында башкарылуы һәм тулылыгы буенча мәгълүмат ачу, шулай ук карау нәтиҗәләре турында хәбәр итү тәртибе.

1.6. Әлеге Регламентта кулланыла торган терминнар һәм билгеләмәләр 294-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланылалар.

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫ ХОКУКЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ ЧИКЛӘҮЛӘРЕ

1.7. Дәүләт комитетының төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан, сәбәпләре аңлатылган язма соратуларга нигезләнеп, тикшерү үткәрү барышында кирәкле мәгълүматны һәм документларны соратып алырга;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан йә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында түләүсез нигездә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 323 номерлы карарында билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә соратып алырга, шул исәптән электрон рәвештә;

3) Россия Федерациясе законнарында каралган тәртипнең бозылуы ачыкланган фактлар буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чараларны күрергә;

4) тикшерү үткәрелә торган юридик зат, индивидуаль эшкуар белән граждан-хокук һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә булмаган һәм тикшерелә торган затларның йогынты ясый алырлык затлары булып тормаган экспертларны, экспертиза оешмаларын тикшерү үткәрүгә җәлеп итәргә.

1.8. Дәүләт комитетының төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә бурычлы:

1) мәҗбүри таләпләрне бозуны кисәтү, ачыклау һәм булдырмый калу буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәргә;

2) Россия Федерациясе законнарын, төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) үткәрелә торган юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

3) Дәүләт комитеты рәисенең (рәисе урынбасарының) тикшерү билгеләнүгә ярашлы рәвештә тикшерү үткәрү турында боерыгы нигезендә тикшерү үткәрү;

4) тикшерүне бары тик хезмәт бурычларын үтәгәндә, күчмә тикшерүне бары тик хезмәт таныклыкларын, Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) боерыгы күчермәсен һәм, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 5 өлешендә каралган очракта, тикшерү үткәрүне килештерү турында документ күчермәсен күрсәтеп үткәрергә;

5) тикшерү үткәрелгәндә җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә анда булуына комачаулык тудырмаска һәм тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

6) тикшерү үткәрелгәндә булган җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына карый торган мәгълүмат һәм документлар бирергә;

7) җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, индивидуаль эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) җитәкчене, башка вазыйфаи затны яки юридик затның вәкаләтле вәкилен, индивидуаль эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга;

9) ачыкланган таләп бозулар фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә күрсәтелгән чараларның таләп бозуларның авырлыгына туры килү-килмәвен исәпкә алырга, шулай ук гражданнар, шул исәптән индивидуаль эшкуарлар, юридик затлар хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең нигезсез чикләнүенә юл куймаска;

10) юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдергән очракта, үз гамәлләренең нигезле булуын дәлилләргә;

11) тикшерү үткәрүнең 294-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән срокларын сакларга;

12) юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан Россия Федерациясе законнарында тапшырылуы каралмаган документларны һәм башка мәгълүматларны таләп итәргә;

13) күчмә тикшерү үткәрелү алдыннан юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар үтенече буенча аларны әлеге Регламентның нигезләмәләре белән таныштырырга;

14) тикшерүләрнең исәбен алып бару журналында, әгәр ул юридик затта, индивидуаль эшкуарда булса, үткәрелгән тикшерү турында язма кертергә;

15) 2016 елның 1 гыйнварыннан алып 2018 елның 31 декабренә кадәрге чорда план буенча тикшерү үткәрелгәндә юридик затның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 статьясы нигезләмәләренең эчтәлеген аңлатырга.

1.9. Дәүләт комитетының төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуксыз:

1) әгәр мәҗбүри таләпләр әлеге вазыйфаи затлар эш йөртә торган Дәүләт комитеты вәкаләтләренә карамаса, аларның үтәлешен тикшерергә;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен, шулай ук кулланылышының мәҗбүрилеге Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен тикшерергә;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә басылып чыкмаган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең һәм таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

4) план буенча һәм планнан тыш тикшерүне аны үткәргәндә юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта үткәрергә;

5) әгәр документлар һәм мәгълүмат тикшерү объектлары яки тикшерү предметлары булмаса, аларны тапшыруны таләп итәргә, шулай ук мондый документларның төп нөсхәләрен тартып алырга;

6) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә билгеле булган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт, закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән мәгълүматны фаш итәргә, моңа Россия Федерациясе законнарында каралган очраклар керми;

7) тикшерү үткәрүгә билгеләнгән срокларны арттырырга;

8) юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга тикшерү буенча чараларны алар хисабыннан үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирүне башкарырга;

9) юридик заттан, индивидуаль эшкуардан башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында йә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмаларда булган, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән документлар һәм (яки) мәгълүмат, шул исәптән рөхсәт бирә торган документлар таләп итәргә;

10) юридик заттан, индивидуаль эшкуардан тикшерү үткәрелә башлау датасына кадәр документлар, мәгълүмат тапшыруны таләп итәргә. Дәүләт комитеты тикшерү үткәрү турында боерык кабул иткәннән соң ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүмат соратып алырга хокуклы.

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ) ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН ЮРИДИК ЗАТНЫҢ, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

1.10. Юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырылганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү үткәрелгәндә, анда турыдан-туры булырга, тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) Дәүләт комитетыннан, Дәүләт комитеты вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына караган һәм бирелүе 294-ФЗ номерлы Федераль законда каралган мәгълүматны алырга;

3) тиешле документлар һәм (яки) мәгълүмат булган башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан йә дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында Дәүләт комитеты тарафыннан алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында сорала торган документларны һәм (яки) мәгълүматны үз инициативасы белән Дәүләт комитетына тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзенең тикшерү тәтиҗәләре белән танышып чыгуы турында, аның белән, шулай ук Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән килешүен яки килешмәвен күрсәтергә;

6) тикшерү үткәргәндә юридик затның, индивидуаль эшкуарның хокукларын бозуга китергән Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл башкармауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирергә;

7) Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне йә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә;

8) әгәр тикшерү план буенча тикшерүләр үткәрүнең еллык планына 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 статьясы нигезләмәләрен бозып кертелгән дип фаразланса, план буенча тикшерүләр үткәрүнең еллык планыннан юридик затка индивидуаль эшкуарга карата тикшерүне төшереп калдыру турында Дәүләт комитетына билгеләнгән тәртиптә гариза тапшырырга.

1.11. Юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тикшерү (күзәтү) чараларын башкарганда Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хокуксыз дип табылган гамәлләре (гамәл башкармаулары) аркасында китерелгән зыянны түләттерергә хокуклы.

1.12. Юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле аларга карата төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырылганда түбәндәгеләргә бурычлы:

1) Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи затыннан сәбәпләре аңлатылган сорату алынган көннән алып ун эш көне эчендә соратуда күрсәтелгән документларны Дәүләт комитеты исеменә җибәрергә (документларга тикшерү үткәрелгәндә);

2) күчмә тикшерү үткәрелгәндә Дәүләт комитетының күчмә тикшерүне үткәрүче вәкаләтле вазыйфаи затларына, әгәр күчмә тикшерүгә кадәр документларга тикшерү үткәрелмәгән булса, тикшерү масатлары, бурычлары һәм предметы белән бәйле булган документлар белән танышу мөмкинлеген бирергә, шулай ук Дәүләт комитетының күчмә тикшерүне үткәрүче вәкаләтле вазыйфаи затларының һәм тикшерүдә катнашучы экспертларның, экспертиза оешмалары вәкилләренең эшчәнлек башкарганда юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан файдаланыла торган территориягә, биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, урыннарга керә алуларын, юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан файдаланыла торган җиһазлар, охшаш объектлар янына килә алуларын тәэмин итәргә;

3) катнашырга яки мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча чаралар оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы вәкаләтле вәкилләрнең катнашуын тәэмин итәргә.

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ГАМӘЛГӘ АШЫРУ НӘТИҖӘЛӘРЕ

1.13. Юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан эшчәнлек гамәлгә ашырылганда мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен системалы күзәтү, мәҗбүри таләпләрнең үтәлеше торышын анализлау һәм фаразлау (алга таба - системалы күзәтү һәм анализ) юлы белән башкарыла торган төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

1) системалы күзәтү һәм анализ уздыру турында хисап (системалы күзәтү һәм анализ уздыру турында хисап формасы Россия Федераль тарифлар хезмәтенең 2014 елның 20 февралендәге 201-э номерлы боерыгы белән расланган);

хокук бозулар ачыклангандa:

2) мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында аларны бетерү сроклары күрсәтелгән күрсәтмә (алга таба - күрсәтмә) (әлеге Регламентка 1 нче кушымтада каралган форма буенча)

3) административ хокук бозу турында беркетмә  (әлеге Регламентка 2 нче кушымтада каралган форма буенча);

4) административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү турында карар (әлеге Регламентка 3 нче кушымтада каралган форма буенча) йә административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктату турында карар (әлеге Регламентка 4 нче кушымтада каралган форма буенча).

1.14. Тикшерүләр юлы белән гамәлгә ашырыла торган төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

1) юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен тикшерү акты (алга таба - тикшерү акты) (тикшерү актының типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган);

2) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

3) тикшерүләрнең исәбен алып бару журналында, әгәр ул юридик затта, индивидуаль эшкуарда булса, үткәрелгән күчмә тикшерү турында язма (тикшерүләрнең исәбен алып бару журналының типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган);

хокук бозулар ачыклангандa:

4) мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында аларны бетерү сроклары күрсәтелгән күрсәтмә (алга таба - күрсәтмә) (әлеге Регламентка 1 нче кушымтада каралган форма буенча);

5) административ хокук бозу турында беркетмә  (әлеге Регламентка 2 нче кушымтада каралган форма буенча);

6) административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү турында карар (әлеге Регламентка 3 нче кушымтада каралган форма

буенча) йә административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктату турында карар (әлеге Регламентка 4 нче кушымтада каралган форма буенча).

Дәүләт функциясен башкару өчен нигез Дәүләт комитетына кергән гражданнарның, шул исәптән индивидуаль эшкуарларның, юридик затларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүмат булса, гариза бирүчегә  дәүләт функциясен башкару нәтиҗәләре буенча җавап 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җибәрелә.

## 2. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН БАШКАРУ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН БАШКАРУ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ БИРҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Дәүләт комитетының урнашу урыны: 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., К.Маркс ур., 66 нчы й.

2.2. Дәүләт функциясен башкару мәсьәләләре буенча документларны һәм мөрәҗәгатьләрне Дәүләт комитетына җибәрү өчен почта адресы: 420015, Татарстан Республикасы,Казан ш., К.Маркс ур., 66 нчы й.

Электрон почта адресы:kt@tatar.ru;

Белешмәләр өчен телефон: (843)2218218.

2.3. Дәүләт комитетының эш графигы:

дүшәмбе - пәнҗешәмбе 9.00 алып 18.00 кадәр;

җомга 9.00 алып 16.45 кадәр;

Төшке аш ялы 13.00 алып 13.45 кадәр.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

2.4. Дәүләт комитетының урнашу урыны, телефоннары һәм эш графигы, почта һәм электрон адреслары турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының kt.tatarstan.ru рәсми сайтына (алга таба тиешенчә - Дәүләт комитетының рәсми сайты, «Интернет» челтәре) һәм Дәүләт комитеты фойесындагы мәгълүмат стендларына урнаштырылган.

Дәүләт функциясен үтәү тәртибе турында мәгълүмат төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар тарафыннан түбәндәгечә бирелә:

1) турыдан-туры шәхси кабул итү кысаларында;

2) язма рәвештә (почта аша алынганда, әлеге Регламентның 2.2 пунктында күрсәтелгән реквизитлар буенча);

3) электрон почта аша (әлеге Регламентның 2.2 пунктында күрсәтелгән электрон адреска мөрәҗәгать иткәндә);

Телдән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгать иткәннән соң ук бирелә, язма мөрәҗәгатькә һәм (яки) электрон почта аша алынган мөрәҗәгатькә җавап әлеге мөрәҗәгать Дәүләт комитетында теркәлгән көннән башлап календарь көннәрдә

исәпләнә торган утыз көнлек срокта, нисбәтле рәвештә, күрсәтелгән почта адресына яки электрон адреска юллана.

Кызыксынулы затларга мәгълүмат бирелүгә карата куелган төп таләпләргә түбәндәгеләр керә: бирелә торган мәгълүматның дөреслеге, мәгълүматны бәян итүдәге төгәллек, бирелә торган мәгълүматның тулылыгы, мәгълүмат алуның уңайлы һәм ачык булуы, мәгълүматның тиз арада бирелүе.

2.5. Дәүләт комитетының http://kt.tatarstan.ru/ рәсми сайтына, мәгълүмат стендларына дәүләт функцияләрен башкару мәсьәләләре буенча түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла:

1) урнашу урыны, элемтәгә керү өчен телефоннар, «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтлар, электрон почта адреслары турында белешмәләр;

2) дәүләт функциясен үтәү тәртибенә кагылышлы Россия Федерациясе законнарының һәм Татарстан Республикасы законнарының төп нигезләмәләре турында мәгълүмат;

3) кушымталары белән әлеге Административ регламентның тексты;

4) дәүләт функциясен үтәү барышы турында мәгълүмат;

5) юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга план буенча тикшерүләр үткәрүнең еллык планы (алга таба - еллык План);

6) тикшерү үткәргәндә юридик затның, индивидуаль эшкуарның хокуклары бозылуга китергән Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү тәртибе.

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ) БУЕНЧА ЧАРАЛАР ҮТКӘРГӘН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРДАН, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРЛАРДАН ТҮЛӘҮ АЛУНЫҢ РӨХСӘТ ИТЕЛМӘВЕ

2.6. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча чаралар үткәргән өчен, шул исәптән мондый тикшерүләргә экспертлар һәм экспертиза оешмалары җәлеп ителгән очракта аларның хезмәтләр күрсәткәне өчен юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан түләү алынмый.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН БАШКАРУ СРОГЫ

2.7. Системалы күзәтү һәм анализ ясау сроклары һәм ешлыгы җайга салына торган эшчәнлек өлкәләрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган мәгълүмат ачу стандартларында билгеләнгән мәгълүмат ачу срокларына һәм ешлыгына туры китереп билгеләнә.

2.8. План буенча тикшерү (һәм документларга, һәм күчмә) һәм планнан тыш тикшерү (һәм документларга, һәм күчмә) үткәрү срогы 20 эш көненнән артык була алмый.

Кече эшкуарлыкның бер субъектына план буенча күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы кече предприятие өчен елына илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артык була алмый.

Дәүләт комитетының план буенча күчмә тикшерүләр үткәрә торган вазыйфаи затларының сәбәпләре аңлатылган тәкъдимнәренә нигезләнгән катлаулы һәм (яки) озак вакытлы тикшеренүләр, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр үткәрү зарур булган аерым очракларда план буенча күчмә тикшерү үткәрү срогы Дәүләт комитеты тарафыннан озайтыла ала, әмма егерме эш көненнән, кече предприятиеләр өчен илле сәгатьтән, микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтән күбрәккә түгел.

Кече эшкуарлык субъектына карата план буенча күчмә тикшерү үткәрү, ведомствоара мәгълүмат алмашу кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат алу таләп ителгән очракта, тикшерү үткәрүне Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) ведомствоара мәгълүмат алмашуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле срокка, әмма иң күбе ун эш көненә, туктатып тора ала. Тикшерү үткәрүне кабат туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору срогы гамәлдә булган чорда кече эшкуарлык субъекты территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында, урыннарында, башка объектларында күрсәтелгән тикшерү белән бәйле Дәүләт комитеты гамәлләре туктатылып тора.

2.9. Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга план буенча тикшерүләр елына иң күбе бер тапкыр үткәрелә.

## ТИКШЕРҮЛӘР, СИСТЕМАЛЫ КҮЗӘТҮ ҮТКӘРҮ ҺӘМ АНАЛИЗ ЯСАУ ӨЧЕН НИГЕЗЛӘР

2.10. Системалы күзәтү үткәрү һәм анализ ясау өчен түбәндәгеләр нигез була:

- юридик затның, индивидуаль эшкуарның Дәүләт комитеты исеменә тарифлар билгеләү турында гариза белән мөрәҗәгать итүе - җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны башкаручы оешмалар өчен;

- Дәүләт комитетына мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә ачылырга тиешле мәгълүматны басма массакүләм мәгълүмат чараларында, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру турында хәбәр итү - Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы табигый монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары өчен;

- ачыла торган мәгълүматны законнар нигезендә урнаштыру (бастырып чыгару) сроклары җитү - Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы табигый монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны башкаручы оешмалар өчен.

2.11. Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга план буенча тикшерүләр Дәүләт комитеты рәисенең (рәис урынбасарының) боерыгы нигезендә Дәүләт комитеты тарафыннан расланган, 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә прокуратура органнары белән килештерелгән еллык Планда каралганча үткәрелә.

2.12. 2018 елның 31 декабренә кадәр «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы нигезләмәләренә ярашлы рәвештә кече эшкуарлык субъектларына кертелгән юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга план буенча тикшерүләр үткәрелми. Әлеге абзацта күрсәтелгән затларга карата элек Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә билгеләнгән тупас хокук бозу башкарылган өчен административ җәза яки дисквалификация рәвешендә административ җәза билгеләнү турында законлы көченә кергән карар чыгарылган булса һәм нәтиҗәдә мондый хөкем чыгарылган йә мондый карар кабул ителгән тикшерү тәгәлләнү датасыннан өч елдан кимрәк вакыт үткән булса, Дәүләт комитеты план буенча тикшерүләр үткәрүнең еллык Планын төзегәндә план буенча тикшерүләр үткәрүнең еллык Планына әлеге Регламентның 2.13 пунктында каралган нигезләр буенча мондый затларга карата тикшерүне кертү турында карар кабул итәргә хокуклы.

2.13. Юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга план буенча тикшерү үткәрүне еллык Планга кертү өчен түбәндәгедән бер ел үтү нигез була:

1) юридик затны, индивидуаль эшкуарны дәүләт теркәвенә алудан;

2) юридик затка, индивидуаль эшкуарга план буенча соңгы тикшерү үткәрү тәгәлләнгәннән.

2.14. Юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга планнан тыш тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуын бетерү турында элек Дәүләт комитеты тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан үтәлү сроклары бетү;

2) Дәүләт комитетына әлеге Регламентның 1.5 пунктындагы «7» һәм «8» пунктчаларында каралган мәгълүматны ачуга карата таләпләрнең юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан үтәлмәве турында гражданнардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар керү, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм массакүләм мәгълүмат чараларыннан белешмәләр алыну;

3) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре буенча йә прокуратура органнарына кергән материаллар һәм

мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбенә нигезләнеп чыгарылган Дәүләт комитеты рәисе боерыгы.

Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуын бетерү турында күрсәтмәнең юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан үтәлү сроклары бетү булса, мондый тикшерүне үткәрүнең предметы дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы һәм (яки) муниципаль контроль органы биргән күрсәтмәне үтәү генә була ала.

2.15. Дәүләт комитетына мөрәҗәгать иткән затны билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук әлеге Регламентның 2.14 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләрне үз эченә алмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмыйлар. Әгәр мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүмат әлеге Регламентның 2.14 пунктындагы 2 пунктча нигезендә планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булса, Дәүләт комитетының вазыйфаи заты, мөрәҗәгатьнең яки гаризаның авторына карата нигезле шиге булган очракта, мөрәҗәгать иткән затның кем булуын билгеләү өчен дөрес чаралар күрергә тиеш. Гариза бирүче электрон документлар рәвешендә юлган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар гариза юллаучы тарафыннан бары тик бердәм идентификация һәм аутентификация системасында гариза бирүченең мәҗбүри авторизациясе каралган мәгълүмат-коммуникация технологияләре чараларын кулланып җибәрелгән очракта гына планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була ала.

2.16. Планнан тыш тикшерү, әгәр ул башланганнан соң аның оештырылуына сәбәп булган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланса йә мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән белешмәләрнең алдан ук дөрес булмавы билгеләнсә, Дәүләт комитеты рәисе, рәисе урынбасары карары белән туктатыла.

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ТУРЫДАН-ТУРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР

2.17. Дәүләт комитетының төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) турыдан-туры гамәлгә ашыручы затларына ТР МК 555 номерлы карары нигезендә түбәндәгеләр керә:

а) рәис һәм төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләрен алып баручы аның урынбасарлары;

б) Дәүләт комитетының структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләрен алып баручы аларның урынбасарлары;

в) Дәүләт комитеты структур бүлекчәләренең «белгечләр» категориясе вазыйфаларының әйдәүче һәм өлкән төркемнәрендәге төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре.

2.18. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) Дәүләт комитетының түбәндәге структур бүлекчәләре вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) коммуналь өлкә оешмаларын җайга салу идарәсенең коммуналь өлкә оешмаларына мониоринг ясау һәм күзәтү бүлегендә:

түбәндәгеләргә карата:

а) кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне, ташландык суны чыгаруны башкаручы оешмаларга;

б) җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга (җылылык энергиясен электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында эшләп чыгаручы оешмалардан тыш);

в) җылылык челтәрләре оешмалары;

г) каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ операторлар;

д) каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторлар;

түбәндәгеләр буенча:

әлеге Регламентның 1.5 пунктындагы «1»-»6», «8» пунктчаларына карата салкын су белән тәэмин итү (эчәргә яраклы суга, техник суга, су кууга, су китерүгә тарифлар), кайнар су белән тәэмин итү (кайнар суга, кайнар суны кууга тарифлар), ташландык суны чыгару (ташландык суны чыгаруга, агып төшкән суларны кууга тарифлар), җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә (җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга китерелә торган җылылык чыганагына тарифлар, җылылык энергиясен, җылылык чыганагын тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар, җылылык энергиясе кулланылмаганда резерв җылылык куәтен саклап тору буенча хезмәтләр күрсәткән өчен түләү, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җылылык белән тәэмин итүнең ачык системаларын кулланып китерелә торган кайнар суга (кайнар су белән тәэмин итү) тарифлар) мәгълүмат ачуны тикшереп тору өлешендә;

әлеге Регламентның 1.5 пунктындагы «7» пунктчасына карата эчәргә яраклы суга (эчәргә яраклы су белән тәэмин итү), техник суга, су кууга, су китерүгә, ташландык суны чыгаруга, агып төшкән суларны кууга, кайнар суга (кайнар су белән тәэмин итү), кайнар су кууга, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җылылык белән тәэмин итүнең ачык системаларын кулланып китерелә торган кайнар суга (кайнар су белән тәэмин итү), җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга китерелә торган җылылык чыганагына тарифлар турында, җылылык энергиясе кулланылмаганда резерв җылылык куәтен саклап тору буенча хезмәтләр күрсәткән өчен расланган түләү турында мәгълүматны, аерым алганда, тарифларны раслау турында карар кабул иткән органның исеме, мондый карарның реквизитлары (датасы һәм номеры), билгеләнгән тарифның зурлыгы, тарифның гамәлдә булу срогы, рәсми басылып чыккан карарның чыганагы турындагы мәгълүматны ачуның дөреслеген тикшереп тору өлешендә;

2) катнаш эшләп чыгаруда җылылык энергиясенә тарифларны җайга салу бүлегендә:

түбәндәгеләргә карата:

җылылык энергиясен (җылылык чыганагын) электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында эшләп чыгаруны (китерүне) гамәлгә ашыручы җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга;

түбәндәгеләр буенча:

әлеге Регламентның 1.5 пунктындагы «1»-»6», «8» пунктчаларына карата җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә (җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан куллланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга китерелә торган җылылык чыганагына тарифлар, җылылык энергиясен, җылылык чыганагын тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар, җылылык энергиясе кулланылмаганда резерв җылылык куәтен саклап тору буенча хезмәтләр күрсәткән өчен түләү) мәгълүмат ачуны тикшереп тору өлешендә;

әлеге Регламентның 1.5 пунктындагы «7» пунктчасына карата җылылык белән тәэмин итүгә расланган тарифлар (җылылык энергиясенә (куәтенә) тарифлар, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан куллланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга китерелә торган җылылык чыганагына тарифлар, җылылык энергиясен, җылылык чыганагын тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар, җылылык энергиясе кулланылмаганда резерв җылылык куәтен саклап тору буенча хезмәтләр күрсәткән өчен түләү) турында мәгълүматның, аерым алганда, тарифларны раслау турында карар кабул иткән органның исеме, мондый карарның реквизитлары (датасы һәм номеры), билгеләнгән тарифның зурлыгы, тарифның гамәлдә булу срогы, рәсми басылып чыккан карарның чыганагы турында ачылган мәгълүматның дөреслеген тикшереп тору өлешендә;

3) электр энергиясенә тарифларны җайга салу бүлегендә:

түбәндәгеләргә карата:

электр энергиясен күмәрләп һәм ваклап сату базарлары субъектларына: түбәндәгеләр буенча:

әлеге Регламентның 1.5 пунктындагы «1»-»6», «8» пунктчаларына карата;

әлеге Регламентның 1.5 пунктындагы «7» пунктчасына карата (билгеләнгән тарифларның зурлыгы турында ачылган мәгълүматның дөреслеген тикшереп тору өлешендә;

4) технологик кушкан өчен түләүне җайга салу һәм тикшерп тору бүлегендә:

түбәндәгеләргә карата:

а) җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга;

5) җылылык челтәрләре оешмаларына;

в) кайнар су белән тәэмин итүче оешмаларга;

9) салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суны чыгаручы оешмаларга.

д) Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны гамәлгә ашыручы табигый монополияләр субъектларына;

түбәндәгеләр буенча:

әлеге Регламентның 1.5 пунктындагы «1»-»6», «8» пунктчаларына карата салкын су белән тәэмин итү, кайнар су белән тәэмин итү, ташландык суны чыгару системаларына тоташтыру (технологик кушу) өлкәсендә, газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны гамәлгә ашыру өлешендә газ белән тәэмин итү өлкәсендә мәгълүмат ачуны тикшереп тору өлешендә;

әлеге Регламентның 1.5 пунктындагы «7» пунктчасына карата салкын су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасына, ташландык суны чыгару үзәкләштерелгән системасына, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасына тоташтыруга расланган тарифлар турында, җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтырган (технологик кушкан) өчен расланган түләү хакында, газ белән тәэмин итү өлкәсендә расланган бәяләр (тарифлар) турында ачылган мәгълүматның, аерым алганда, тарифларны раслау турында карар кабул иткән органның исеме, мондый карарның реквизитлары (датасы һәм номеры), билгеләнгән тарифның зурлыгы, тарифның гамәлдә булу срогы, рәсми басылып чыккан карарның чыганагы турында ачылган мәгълүматның дөреслеген тикшереп тору өлешендә;

5) административ тәҗрибә бүлегендә административ хокук бозулар турында эшләр кузгату һәм административ хокук бозуларга юл куйган затларны административ җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү өлешендә.

2.19. Тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла торган төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турыдан-туры Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) боерыгы белән тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.20. Дәүләт функциясен башкаруга тикшерү үткәрелә торган юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән граждан-хокук һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә булмаган һәм тикшерелә торган затларның йогынты ясый алырлык затлары булып тормаган экспертлар, экспертиза оешмалары җәлеп ителергә мөмкин.

## 294-ФЗ НОМЕРЛЫ ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОННЫ БОЗГАН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРНЫҢ, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

2.21. 294-ФЗ номерлы Федераль законның бозылуына юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез каршылык күрсәтүче, тикшерүләр үткәрүдән качучы һәм (яки) мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуларын бетерү турында Дәүләт комитеты күрсәтмәсенең билгеләнгән срогын үтәмәүче юридик затлар, аларның җитәкчеләре, юридик затларның башка вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре, индивидуаль эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

## ТИКШЕРҮ ҮТКӘРГӘНДӘ ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫНЫҢ, АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

2.22. Дәүләт комитеты, аның вазыйфаи затлары функцияләрен, хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгән, тикшерү үткәргәндә хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәлләр кылмаган) очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында Дәүләт комитеты хокуклары һәм (яки) мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, индивидуаль эшкуарга мондый чаралар күрелгән көннән алып ун көн эчендә язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

## 3. ЮРИДИК ЗАТЛАРГА, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРЛАРГА КАРАТА КУЕЛА ТОРГАН МӘҖБҮРИ ТАЛӘПЛӘР

3.1. Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата куела торган, үтәлеше Дәүләт комитеты тарафыннан тикшерелеп тора торган мәҗбүри таләпләр исемлеге, мәҗбүри таләпләр куела торган эшчәнлек төрләре, таләпләр төрләре, мәҗбүри таләпләр билгели торган норматив хокукый актлар күрсәтелеп, 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица - Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата куела торган, үтәлеше Дәүләт комитеты тарафыннан тикшерелеп тора торган мәҗбүри таләпләр исемлеге

<table>
<tr><th>№ т/б</th><th>Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектлары</th><th>Мәҗбүри таләпнең эчтәлеге</th><th>Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив хокукый акт</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td></tr>
<tr><td>1</td><td>Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ кую өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы табигый монополияләр субъектлары</td><td rowspan="4">Җайга салына торган оешмалар тарафыннан түбәндәгеләр үтәлү:<br>- мәгълүмат ачу факты;<br>- мәгълүмат басылып чыгу чыганагы;<br>- мәгълүмат ачу сроклары һәм ешлыгы;<br>- мәгълүмат ачуның тулылыгы;<br>- мәгълүмат басылып чыгу чыганаклары турында Дәүләт комитетына хәбәр итү тәртибе;<br>- мәгълүмат тапшыру формалары һәм билгеләнгән тәртиптә расланган бу формаларны тутыру кагыйдәләренең</td><td>147-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 5 өлеше, 8.1 статьясы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 29 октябрендәге 872 номерлы карары;<br>Россия Тарифлар буенча федераль хезмәтенең 2011 елның 31 гыйнварындагы 36-э номерлы боерыгы</td></tr>
<tr><td>2</td><td>электр энергиясен күмәрләп сату базары субъектлары (Россия Федерациясе субъектының җайга салучы органы компетенциясенә караган өлешендә)</td><td rowspan="2">147-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 5 өлеше, 8.1 статьясы;<br>35-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 3 өлеше;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 21 гыйнварындагы 24 номерлы карары</td></tr>
<tr><td>3</td><td>электр энергиясен ваклап сату базары субъектлары</td></tr>
<tr><td>4</td><td>җылылык белән тәэмин итүче оешмалар</td><td>147-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 5 өлеше, 8.1 статьясы;</td></tr>
</table>

<table>
<tr><th>№<br>т/б</th><th>Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектлары</th><th>Мәҗбүри таләпнең эчтәлеге</th><th>Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив хокукый акт</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td></tr>
<tr><td>5</td><td>җылылык челтәрләре оешмалары</td><td rowspan="4">үтәлүе;<br>- ачылган мәгълүматның дөреслеге;<br>- юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның товарларын кулланучыларның һәм хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның язмача соратулары буенча, шул исәптән язмача соратуларны теркәү, аларны карауның үз вакытында башкарылуы һәм тулылыгы буенча мәгълүмат ачу, шулай ук карау нәтиҗәләре турында хәбәр итү тәртибе</td><td>190-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 11 өлеше;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 июлендәге 570 номерлы карары;<br>Россия Тарифлар буенча федераль хезмәтенең 2017 елның 14 июлендәге 930/17 номерлы боерыгы</td></tr>
<tr><td>6</td><td>каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ операторлар</td><td rowspan="2">89-ФЗ номерлы Федераль законның 24.11 статьясындагы 2 өлеше, 24.12 статьясы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары</td></tr>
<tr><td>7</td><td>каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторлар</td></tr>
<tr><td>8</td><td>кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны башкаручы оешмалар</td><td>147-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 5 өлеше, 8.1 статьясы;<br>416-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясы, 35 статьясы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары;<br>Россия Тарифлар буенча федераль хезмәтенең 2017 елның 19 гыйнварындагы 792/17 номерлы боерыгы</td></tr>
</table>

3.2. Юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең бозылуын кисәтү, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны бетерү максатларында Дәүләт комитеты, ел саен үзе раслый торган дәүләт тарафыннан бәяләрне (тарифларны) җайга салу өлкәсендә мәҗбүри таләпләрнең бозылуын профилактикалау программасына ярашлы рәвештә, мәҗбүри таләпләрнең бозылуын профилактикалау чараларын гамәлгә ашыра.

3.3. Юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән үзара хезмәттәшлектә тормыйча гамәлгә ашырыла торган тикшерү чараларын гамәлгә ашыру барышында алынган йә Дәүләт комитетына кергән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторының кем булуы билгеләнмәгән мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан тыш), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматта мәҗбүри таләпләрне бозарга уйлау турында яки андый бозуларның билгеләре булу турында белешмәләр булган очракта, әгәр юридик зат, индивидуаль эшкуар элек тиешле таләпләрне бозган өчен җаваплылыкка тартылмаган булса, Дәүләт комитеты юридик затка, индивидуаль эшкуарга мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамавы турында искәрмә чыгара һәм юридик затка, индивидуаль эшкуарга мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта мондый искәрмәдә билгеләнгән срокта Дәүләт комитетына хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.4. Мәҗбүри таләпләрне бозуның ярамавы турында кисәтүне төзү һәм юллау, юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан мондый искәрмәгә ризасызлык белдерү һәм аларны карау, мондый кисәтүнең үтәлүе турында хәбәр итү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. ТИКШЕРҮ ҮТКӘРЕЛГӘНДӘ ЮРИДИК ЗАТ, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАР ТАРАФЫННАН ТАПШЫРЫЛА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР

Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан тапшырыла торган документларның, шулай ук мондый документларның формаларын раслый торган норматив хокукый актларның исемлеге 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица. Тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

| т/б № | Тикшерү үткәрү өчен тапшырыла торган документ | Документның формасын билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 1 | Гражданның, индивидуаль эшкуарның, юридик зат законлы вәкиленең, аларның вәкаләтле вәкилләренең шәхесен таныклый торган документ | |
| 2 | Юридик затның, индивидуаль эшкуарның яки гражданның мәнфәгатьләрен белдерүче затның вәкаләтләрен раслый торган документлар | |
| 3 | Һәркем ирекле файдалана алырлык тиешле мәгълүматны бирү турында кулланучылардан юридик зат, индивидуаль эшкуар исеменә алынган язма мөрәҗәгатьләрне теркәүне раслый торган документлар | |
| 4 | Һәркем ирекле файдалана алырлык тиешле мәгълүматны бирү турында кулланучылардан юридик зат, индивидуаль эшкуар исеменә алынган язма мөрәҗәгатьләргә җавапларның күчермәләре | |
| 5 | Мәгълүмат ачу турында законнарда билгеләнгән очракларда һәм күләмнәрдә басма чыганакларда ачылырга тиешле мәгълүмат басылып чыккан басма чыганаклар | |

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ (ГАМӘЛЛӘРНЕҢ) СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОКЛАРЫ, АЛАРНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН БАШКАРУ КЫСАЛАРЫНДА ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ

5.1. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) түбәндәге административ процедуралар ярдәмендә гамәлгә ашырыла:

1) системалы күзәтү һәм анализ;

2) план буенча тикшерүләр үткәрүне планлаштыру;

3) юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның документларына план буенча тикшерүләр үткәрү;

4) юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга план буенча күчмә тикшерүләр үткәрү;

5) юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның документларына планнан тыш тикшерүләр үткәрү;

6) юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга планнан тыш күчмә тикшерүләр үткәрү.

5.2. Дәүләт функциясен башкаруның блок-схемалары әлеге Регламентка 5 нче һәм 6 нчы кушымталарда китерелгән.

5.3. Дәүләт функциясен башкаруны туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда рөхсәти ителә.

## «СИСТЕМАЛЫ КҮЗӘТҮ ҺӘМ АНАЛИЗ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.4. Системалы күзәтү үткәрү һәм анализ ясау өчен әлеге Регламентның 2.10 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез була.

5.5. Системалы күзәтү һәм анализ юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә гамәлгә ашырыла һәм үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1) мәгълүматны «Интернет» челтәренә һәм массакүдәм мәгълүмат чараларына урнаштырганда мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтүне;

2) юридик затның һәм индивидуаль эшкуарның эшчәнлеге йә гамәлләре турында мәгълүматка, мондый затларга аны бирү бурычы (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системаларын кулланып) федераль закон нигезендә йөкләнгән, анализ ясау аша мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтүне.

Юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән хезмәттәшлек итмичә тикшерү чаралары мондый чараларны үткәрүгә Дәүләт комитеты рәисе яки Дәүләт комитеты рәисе урынбасары тарафыннан раслана торган йөкләмәләргә нигезләнеп үткәрелә. Йөкләмәләрнең типлатырылган формалары Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнә.

5.6. Әлеге Регламентның 1.5 пунктындагы «1» – «6» пунктчаларына кагылышлы системалы күзәтү һәм анализ аларның вәкаләтләренә һәм әлеге Регламентның 2.18 пунктында күрсәтелгән Дәүләт комитеты бүлекләре компетенциясенә ярашлы рәвештә үткәрелә. Һәр юридик зат, индивидуаль эшкуар буенча Дәүләт комитетының тиешле бүлеге башлыгы (алга таба – бүлек башлыгы) ачылган мәгълүматка системалы күзәтү үткәрү һәм анализ ясау өчен җаваплы вазыйфаи затны (алга таба –җаваплы башкаручы) билгели.

5.7. Системалы күзәтү үткәргәндә һәм анализ ясаганда җаваплы башкаручы түбәндәге гамәлләрне гамәлгә ашыра:

1) юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның исемлеген төзү;

2) документлар һәм материаллар җыю;

3) документларны һәм материалларны эшкәртү һәм анализлау;

4) системалы күзәтү үткәрү һәм анализ ясау турында хисап әзерләү.

5.8. Системалы күзәтү үткәрелергә һәм анализ ясалырга тиешле юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның исемлекләре әлеге Регламентның 2.18 пунктында күрсәтелгән Дәүләт комитеты бүлекләренең компетенциясенә ярашлы рәвештә җаваплы башкаручылар тарафыннан төзелә һәм Дәүләт комитеты рәисенең тиешле эшчәнлек өлкәсен алып баручы урынбасары тарафыннан раслана (әлеге Регламентка 7 нче кушымтада каралган форма буенча).

Башкару срогы: төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру чорына кадәрге елның 1 декабренә кадәр.

Гамәл нәтиҗәсе: системалы күзәтү үткәрелергә һәм анализ ясалырга тиешле юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның исемлеге.

5.9. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметына караган документларны һәм материалларны җыю рәсми басма чыганакларда, юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның сайтларында, Дәүләт комитетының рәсми сайтында (kt.tatarstan.ru) төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметына караган мәгълүматны барлау юлы белән башкарыла.

Җаваплы башкаручы «Интернет» челтәрендә мәгълүматның урнашу урыны, шулай ук аның рәсми басма чыганакларда басылып чыгуы турында юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар җибәргән хәбәрнамәләрнең исәбен алып бара.

Башкару срогы: мәгълүмат ачу стандартларында юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар өчен билгеләнгән мәгълүмат ачу срогы беткән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәл нәтиҗәсе: «Интернет» челтәрендә һәм рәсми басма чыганакларда табылган дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметына караган мәгълүмат.

5.10. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм материалларны җыю нәтиҗәләре буенча җаваплы зат түбәндәгеләрне билгеләү өчен документларны һәм материалларны эшкәртә һәм анализлый:

1) бастырып чыгару чыганагында ачылган мәгълүматның булуын;

2) юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларында билгеләнгән мәгълүматны урнаштыру срокларының һәм ешлыгының үтәлүен;

3) юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан ачылган мәгълүмат исемлегенең мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп ачылырга тиешле мәгълүмат исемлегенә туры килүен, шулай ук мәгълүмат ачу формаларының юридик зат, индивидуаль эшкуар искәрмәләре белән расланмаган тутырылмаган юлларның калу-калмавын;

4) бирелгән белншмәләрнең дөреслеген һәм хәбәр итү срокларының мәгълүмат ачу стандартларында каралган срокларына туры килүен;

5) ачылган мәгълүматның аны ачуның расланган формаларына туры килүен.

Башкару срогы: мәгълүматны, документларны һәм материалларны эшкәртү һәм анализлау әлеге Регламентның 5.9 пунктында каралган процедура төгәлләнгән

көннән 30 эш көненнән дә соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартлары таләпләренең үтәлүен бәяләү.

5.11. Җаваплы башкаручы мәгълүматны, документларны һәм материалларны эшкәртү һәм анализлау буенча кирәкле гамәлләрне үткәрү нәтиҗәләре буенча системалы күзәтү үткәрү һәм анализ ясау турында хисапны рәсмиләштерә (системалы күзәтү ткәрү һәм анализ ясау турында хисап формасы Россия Тарифлар буенча федераль хезмәтенең 2014 елның 20 февралендәге 201-э номерлы боерыгы белән расланган).

«Интернет» челтәрендә һәркем ирекле файдалана алырлык булырга тиешле мәгълүматның тулысынча ачылмавы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы мәгълүмат ачу стандартларында каралган мәгълүматны үз эченә алган сайт битләре булган экранны төшерә (скриншот), аларны бастырып чыгара, номер суга һәм, бастыру вакытын һәм датасын күрсәтеп, имзасы белән таныклый.

Хисап, каралган материаллар, ә таләпләр бозылу ачыкланган очракта – экран төшермәләре (скриншотлар) танышу өчен бүлек башлыгына тапшырыла, шуннан соң Дәүләт комитеты рәисенең Дәүләт комитеты эшчәнлегенең тиешле юнәлешен алып баручы  урынбасары каравына бирелә.

Системалы күзәтү үткәрү һәм анализ ясау турында хисап, Дәүләт комитеты архивына тапшырылганчы, белгечләре системалы күзәтүне һәм анализны гамәлгә ашыра торган бүлекләрдә саклана.

Башкару срогы: әлеге Регламентның 5.10 пунктында каралган процедуралар төгәлләнгән көннән башлап 10 эш көненнән дә соңга скалмыйча.

Гамәл нәтиҗәсе: системалы күзәтү үткәрү һәм анализ ясау турында хисап.

5.12. Мәгълүмат ачу стандартларының бозылуы ачыкланган очракта Дәүләт комитеты:

1) мәгълүмат ачу стандартларын  ачыкланган бозуның юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан бетерелүе турында күрсәтмә бирә;

2) Дәүләт комитеты вәкаләтләре нигезендә административ хокук бозулар турында эшләр кузгата.

Әлеге Регламентның 2.18 пунктындагы 1 –4 пунктчаларында күрсәтелгән бүлекләрнең җаваплы башкаручылары системалы күзәтү үткәрү һәм анализ ясау йомгаклары буенча, системалы күзәтү үткәрү һәм анализ ясау турында хисап төзелгән датадан өч эш көненнән дә соңга калмыйча, ачыкланган бозуларга юл куйган вазыйфаи затларны һәм юридик затларны административ җаваплылыкка тарту буенча эшне алга таба оештыру өчен хисапның күчермәсен Дәүләт комитетының административ практика бүлегенә  тапшыралар.

Административ практика бүлеге:

– күрсәтмә проектын әзерли (әлеге Регламентка 3 нче кушымтада каралган форма буенча) һәм аны килештерү өчен бүлекләр башлыкларына, Дәүләт комитеты рәисенең шул юнәлешне алып баручы урынбасарына һәм кул кую өчен Дәүләт комитеты рәисенә җибәрә;

– кул куелганнан соң күрсәтмәне юридик затка, индивидуаль эшкуарга гомуми эш башкару тәртибендә (тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы хат белән) юллый йә юридик затның, индивидуаль эшкуарның законлы вәкиленә (вәкаләтләр бирелгән вәкиленә), аның имзасын алып, кулына тапшырыла.

Башкару срогы: ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында күрсәтмә, системалы күзәтү үткәрү һәм анализ ясау турында хисап алынган датадан өч эш көненнән дә соңга калмыйча, әзерләнергә һәм Дәүләт комитеты рәисенә имза салу өчен җибәрелергә тиеш.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затка, индивидуаль эшкуарга җибәрелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә.

5.13. Административ хокук бозулар турында кузгатылган эшнең Дәүләт комитеты тарафыннан каралуы нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе чыгарыла:

әлеге Регламентка 3 нче кушымтада каралган форма буенча административ җәза билгеләү турында карар;

әлеге Регламентка 4 нче кушымтада каралган форма буенча административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктату турында карар.

Башкару срогы: административ хокук бозулар турында беркетмә төзелгән вакыттан алып унбиш көн эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү турында карар йә административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктату турында карар.

5.14. Административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү турында карарның күчермәсе йә административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктату турында карарның күчермәсе ул кемгә карата чыгарылган, шул физик затка яки физик затның законлы вәкиленә, яки юридик затның законлы вәкиленә кул куйдыртып тапшырыла йә күрсәтелгән затларга тапшырылу турында хәбәр ителә торган заказлы почта юлламасы белән җибәрелә.

Башкару срогы: административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү турында йә административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктату турында карар чыгарылган көннән алып өч көн эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затка яки индивидуаль эшкуарга тапшырылган яки җибәрелгән административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү турында карарның күчермәсе йә административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктату турында карарның күчермәсе.

## «ПЛАН БУЕНЧА ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮНЕ ПЛАНЛАШТЫРУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.15. «План буенча тикшерүләр үткәрүне планлаштыру» административ процедурасын башлау өчен нигез еллык План әзерләү срокларының җитүе була.

5.16. Еллык план, төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру функциясен башкаручы бүлекләрнең тәкъдимнәрен исәпкә алып, 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә административ практика бүлеге тарафыннан эшләнә.

Еллык планны әзерләү , шул исәптән аны прокуратура органнарына тапшыру һәм прокуратура органнары белән килештерү тәртибе һәм сроклары, шулай ук еллык планның типлаштырылган формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карарында билгеләнгән.

Юридик затны, индивидуаль эшкуарны план буенча тикшерүне еллык Планга кертү өчен әлеге Регламентның 2.13 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез була.

5.17. Административ практика бүлеге башлыгы еллык Планны әзерләү өчен җаваплы башкаручыны (җаваплы башкаручыларны) билгели (алга таба – еллык Планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы).

Башкару срогы: план буенча тикшерүләр үткәрү елына кадәрге елның 1 августыннан да соңга калмыйча.

5.18. Еллык Планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы түбәндәге административ гамәлләр башкара:

1) билгеләнгән форма буенча еллык План проектын төзи;

2) аны төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру функцияләренә кертелгән бүлекләрнең башлыклары, Дәүләт комитеты рәисенең тиешле эшчәнлек өлкәсен алып баручы урынбасарлары, Дәүләт комитеты рәисе белән килештерә;

башкару срогы: план буенча тикшерүләр үткәрү елына кадәрге елның 31 августына кадәр;

3) еллык План проектын карау өчен план буенча тикшерүләр үткәрү планлаштырылган юридик затның, индивидуаль эшкуарның урнашу урыны буенча прокуратура органына түбәндәгечә җибәрә: тапшырылу турында хәбәр ителәə торган заказлы почта юлламасы белән кәгазьдә (электрон рәвештәге күчермәсен беркетеп) йә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза салынган электрон документ рәвешендә;

башкару срогы: план буенча тикшерүләр үткәрү елына кадәрге елның 1 сентябренә кадәр.

Гамәл нәтиҗәсе: прокуратура органнарына карау өчен җибәрелгән еллык План проекты.

5.19. Еллык План проектын прокуратура органнары караганнан соң һәм тәкъдимнәр кертелгәннән соң еллык Планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы:

1) еллык План проектын прокуратура органнарыннан кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып төзәтә;

2) кертелгән үзгәрешләр белән еллык План проектын төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру функцияләре кертелгән бүлекләрнең башлыклары, Дәүләт комитеты рәисенең тиешле эшчәнлек өлкәсен алып баручы урынбасарлары белән килештерә;

3) еллык План проектын раслау өчен Дәүләт комитеты рәисенә җибәрә;

4) еллык План Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан расланганнан соң аны прокуратура органнарына аларга тапшырылу турында хәбәр ителәə торган заказлы почта юлламасы белән кәгазьдә (электрон рәвештәге күчермәсен беркетеп) йә

көчәйтелгән квалификацияле электрон имза салынган электрон документ рәвешендә җибәрә;

Башкару срогы: план буенча тикшерүләр үткәрү елына кадәрге елның 1 ноябренә кадәр.

Гамәл нәтиҗәсе: прокуратура органнарына җибәрелгән расланган еллык План.

5.20. Еллык Планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы Дәүләт комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә расланган еллык Планны Дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштыру турында хезмәт хаты юллый.

Башкару срогы: еллык Планны Дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштыру – план буенча тикшерүләр үткәрүнең расланган тиешле бердәм җыелма еллык планы Татарстан Республикасы прокуратурасы сайтына урнаштырылган вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәл нәтиҗәсе: Дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштырылган еллык План.

5.21. Еллык Планга үзгәрешләр кертү, Дәүләт комитеты боерыгына нигезләнеп, еллык планнарны әзерләү Кагыйдәләрендә билгеләнгән очракларда рөхсәт ителә. Еллык Планга кертелгән үзгәрешләр турында белешмәләр алар билгеләнгән тәртиптә кертелгән көннән алып 3 эш көне эчендә тиешле прокуратура органына аңа тапшырылу турында хәбәр ителә торган заказлы почта юлламасы белән кәгазьдә (электрон рәвештәге күчермәсен беркетеп) йә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза салынган электрон документ рәвешендә җибәрелә, шулай ук Дәүләт комитетының рәсми сайтына, үзгәрешләр кертелгән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

## «ЮРИДИК ЗАТЛАРНЫҢ, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРЛАРНЫҢ ДОКУМЕНТЛАРЫНА ПЛАН БУЕНЧА ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.22. «Юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның документларына план буенча тикшерүләр үткәрү» административ процедурасын башлап җибәрү өчен юридик затны, индивидуаль эшкуарның еллык Планга кертелүе һәм юридик затка, индивидуаль эшкуарга план буенча тикшерү үткәрү сроклары җитү.

Административ процедура административ гамәлләрнең түбәндәге тәртибенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла:

1) тикшерү үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү;

2) тикшерүне үткәрү турында боерыкны рәсмиләштерү;

3) тикшерү үткәрелү турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга хәбәр итү;

4) тикшерүне үткәрү;

5) тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү, шул исәптән мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуын бетерү буенча чаралар күрү.

5.23. Дәүләт комитетының үз компетенциясе чикләрендә тикшерү үткәрүче бүлекләре башлыклары Еллык План нигезендә юридик затка, индивидуаль эшкуарга тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны

билгели.

Башкару срогы: тикшерүне үткәрү башланганчы 10 эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән вәкаләтле вазыйфаи затларның һәм җаваплы башкаручынының исемлеге.

5.24. Җаваплы башкаручы:

1) юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның документларына план буенча тикшерү  үткәрү турында боерык проектын әзерли (Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча);

2) боерык проектын Дәүләт комитеты рәисенә (рәисе урынбасарына) имза куярга җибәрә.

Башкару срогы: тикшерүне үткәрү башланганчы җиде эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәл нәтиҗәсе: Дәүләт комитеты рәисе (рәисе урынбасары) имзалаган юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның документларына план буенча тикшерү  үткәрү турында боерык.

5.25. Дәүләт комитеты юридик затка, индивидуаль эшкуарга документларга план буенча тикшерү  үткәрү турында Дәүләт комитеты рәисенең (рәис урынбасарының) боерыгы күчермәсен, тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы почта хаты белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, индивидуаль эшкуарның электрон почта адресына, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән булса, йә элегрәк Дәүләт комитетына юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан тапшырылган булса, электрон документ ярдәмендә яки башка мөмкин булган ысул белән (факсимиль элемтә, элетрон почта аша, алу турында тамга куеп кулга биреп) хәбәр итә.

Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары документларга план буенча тикшерүне үткәрә башлаганчы юридик затның җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, ндивидуаль эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.1 статьясы нигезләмәләренең эчтәлеген аңлата. Документларга план буенча тикшерү үткәрелә торган юридик затны, индивидуаль эшкуарны әлеге Регламентның 2.12. пунктында күрсәтелгән затларга кертүне раслый торган документлар документларга план буенча тикшерү үткәрелгәндә Дәүләт комитеты вазыйфаи затларына тапшырылган очракта һәм  әлеге Регламентның 2.12 пунктында каралган нигезләр булмаганда, документларга план буенча тикшерү үткәрү туктатыла, бу хакта тиешле акт төзелә.

Тикшерү үз-үзен җайга сала торган оешманың әгъзасы булган юридик затка, индивидуаль эшкуарга үткәрелгән очракта, җаваплы башкаручы шулай ук үз-үзен җайга сала торган оешмага аның вәкиленең план буенча документларга тикшерү үткәрелгәндә катнашу яки булу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында хәбәрнамә юллый.

Башкару срогы: тикшерүне үткәрү башланганчы 3 эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәл нәтиҗәсе: документларга план буенча тикшерү үткәрелү турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга хәбәр итү.

5.26. Юридик зат, индивидуаль эшкуар боерык күчермәсен алган вакыттан 10 эш көне эчендә Дәүләт комитетына документларга план буенча тикшерү үткәрелү турында боерыкта күрсәтелгән документларны җибәрергә тиеш.

Күрсәтелгән документлар мөһер белән (булган очракта) һәм тиешенчә индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, җитәкчесе, юридик затның башка вазыйфаи заты имзасы белән таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла. Юридик зат, индивидуаль эшкуар соратуда күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә җибәрергә хокуклы.

Дәүләт комитетына тапшырыла торган документлар күчермәләренең, әгәр башкасы Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса, нотариаль таныклануын таләп итү рөхсәт ителми.

Дәүләт комитеты юридик заттан, индивидуаль эшкуардан Дәүләт комитеты тарафыннан башка дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуксыз.

5.27. Тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар Дәүләт комитеты карамагында булган документлардагы белешмәләргә һәм юридик залар, индивидуаль эшкуарлар тапшырган документлардагы белешмәләргә нигезләнеп:

1) белешмәләрнең дөреслеген бәялиләр;

2) документлардагы белешмәләргә юридик зат, индивидуаль эшкуар эшчәнлегенең билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры килү-килмәвенә бәя бирәләр.

Документларга тикшерү үткәрү барышында юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан тапшырылган документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар булу йә бу документлардагы белешмәләрнең Дәүләт комитетында булган документлардагы белешмәләргә туры килмәве ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы:

юридик затка, индивидуаль эшкуарга белешмәләрне бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирелгән һәм 10 эш көне эчендә язма рәвештә аңлатмалар бирү һәм башка кирәкле документларны тапшыру таләбе куелган хат (сәбәпләре аңлатылган сорату) әзерли;

- хатны (сәбәпләре аңлатылган соратуны) Дәүләт комитеты рәисенә (рәис урынбасарына) имза куярга җибәрә;

имза салынганнан соң хатны (сәбәпләре аңлатылган соратуны), Дәүләт комитеты рәисе боерыгының күчермәсен беркетеп, юридик зат, индивидуаль эшкуар адресына аларга тапшырылуы турында хәбәр итеп торган заказлы почта юлламасы белән йә башка мөмкин булган ысул белән (факсимиль элемтә, элетрон почта аша, алу турында тамга куеп кулга биреп) җибәрә.

Тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) каршылыкларга кагылышлы аңлатмаларны Дәүләт комитетына тапшыручы юридик зат, индивидуаль эшкуар Дәүләт комитетына өстәмә рәвештә элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документлар тапшырырга хокуклы.

Аңлатмаларны һәм (яки) элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документларны алганнан соң, тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан тапшырылган аңлатмаларны һәм (яки) элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документларны карыйлар, һәм җаваплы башкаручы тикшерү актын төзи.

Тапшырылган аңлатмаларны һәм (яки) элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документларны караганнан соң йә аңлатмалар булмаган чакта Дәүләт комитеты мәҗбүри таләпләрнең бозылу билгеләре булуны тәгаенләсә, Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы. Бу очракта җаваплы башкаручы күчмә тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерли. Күчмә тикшерү үткәрү турында карарны Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) кабул итә. Бу вакытта документларга тикшерү нәтиҗәләре дәүләт функциясен башкарганда административ процедураны күчмә тикшерү рәвешендә гамәлгә ашыруны башлау өчен булган нигезгә туры киләчәк. Күчмә тикшерүне үткәргәндә юридик заттан, индивидуаль эшкуардан документларга тикшерү үткәрү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм мәгълүматны тапшыруларын таләп итү тыела.

Башкару срогы: әлеге Регламентның 2.8 пункты таләпләре нигезендә тикшерүләр үткәрү срогы.

Гамәл нәтиҗәсе: каралган документлар, шул исәптән юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар тарафыннан тапшырылган аңлатмалар һәм документлар; кирәк булган очракта, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык проекты.

5.28. Тапшырылган документлар һәм мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы ике нөсхәдә тикшерү актын төзи (тикшерү үткәрү турында актның типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган), алар тикшерү үткәргән вазыйфаи затлар тарафыннан имзалана.

Тикшерү нәтиҗәсендә юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының бозылуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы түбәндәге гамәлләрне башкара:

1) тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар тапшырган тикшерү нәтиҗәләренә нигезләнеп, ачыкланган бозуларны тикшерү актына теркәп куя;

2) тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан тапшырылган аларның компетенциясенә кергән өлешендә күрсәтмәләр проектларына нигезләнеп, тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында Дәүләт комитеты күрсәтмәсенең җыелма проектын әзерли, анда аларны бетерү сроклары күрсәтелә (әлеге Регламентка 1 нче кушымтада каралган форма буенча), аңа Дәүләт комитеты

рәисе кул куя. Дәүләт комитеты күрсәтмәсенең билгеләнгән срокларда үтәлешен тикшереп тору бүлек компетенциясенә ярашлы рәвештә тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Документларга тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү актын рәсмиләштергәндә җаваплы башкаручы, кирәк булган очракта, аңа түбәндәгеләрне беркетә:

үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар һәм экспертизалар беркетмәләрен яки бәяләмәләрен;

мәҗбүри таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнә торган юридик зат вазыйфаи затларының (вәкилләренең), индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең аңлатмаларын;

тикшерү нәтиҗәләренә бәйле булган башка документлар яки аларның күчермәләре.

Административ хокук бозулар билгеләре ачыкланган очракта административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча беркетмәләр төзергә вәкләтле вазыйфаи зат, Дәүләт комитетының вәкаләтләренә туры китереп, РФ КоАП 9.15, 19.8.1 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында эшләр кузгата.

Җаваплы башкаручы тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталарның күчермәләре белән бергә) делога тегеп куя һәм аны Дәүләт комитеты архивына билгеләнгән тәртиптә тапшырганчы саклый, икенчесен (кушымталарның күчермәләре белән бергә), тикшерү акты белән танышу турында йә танышудан баш тарту турында кул куйдыртып, җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга яки аның вәкаләтле вәкиленә тапшыра.

Җитәкче, башка вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышу турында йә танышудан баш тарту турында расписка бирүдән баш тарткан очракта, акт аның тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы почта юлламасы белән җибәрелә, ул Дәүләт комитеты эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә беркетеп куела. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек башкаруга тикшерелә торган затның ризалыгы булган очракта, тикшерү акты бу актны төзегән затның квалификацияле көчәйтелгән электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, индивидуаль эшкуарга яки аның вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Бу очракта тикшерелә торган затка әлеге актны төзегән затның квалификацияле көчәйтелгән электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрелгән акт тикшерелә торган зат тарафыннан алынган дип санала.

Башкару срогы:

кушымталары булган тикшерү актын төзү һәм тапшыру: турыдан-туры тикшерү тәгәлләнгәннән соң (тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алу кирәк

булган очракта, тикшерү акты тикшерү чаралары төгәлләнгәннән соң өч эш көненнән артык булмаган срокта төзелә);

тикшерү акты күрсәтелгән очракта тапшыырылу турында хәбәр ителә торган заказлы хат белән һәм (яки) актны төзегән затның квалификацияле көчәйтелгән электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрү – тикшерү чаралары төгәлләнгәннән соң килүче бер эш көне дәвамында;

тикшерү актын Дәүләт комитеты структур бүлекчәсендә төзелү урыны буенча саклау: норматив актларда билгеләнгән сроклар дәвамында аның Дәүләт архивына билгеләнгән тәртиптә тапшырылуына кадәр.

Гамәл нәтиҗәсе: ике нөсхәдә кушымталар белән тикшерү акты, аларның берсе юридик затка, индивидуаль эшкуарга тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе делога тегеп куелган һәм Дәүләт комитеты структур бүлекчәсендә төзелү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә саклана.

Тикшерү үткәрелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән йә ачыкланган бозуларны әетерү турында бирелгән күрсәтмә белән килешмәгән очракта, тикшерү актын алган датадан алып унбиш көн эчендә Дәүләт комитетына тикшерү актына һәм (яки) ачыкланган бозуларны әетерү турында бирелгән күрсәтмәгә карата тулаем яки аның кайбер нигезләмәләре буенча ризасызлыгын язма рәвештә бирергә хокуклы. Бу вакытта юридик зат, индивидуаль эшкуар мондый ризасызлыкларга әлеге ризасызлыкларның нигезләнгән булуын исбатлый торган документларны яки аларның таныкланган күчермәләрен беркетергә йә аларны килешенгән срокта Дәүләт комитетына тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның квалификацияле көчәйтелгән электрон имзасы белән имзаланган электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

5.29. Административ хокук бозулар турында кузгатылган эшнең Дәүләт комитеты тарафыннан каралуы нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе чыгарыла:

әлеге Регламентка 3 нче кушымтада каралган форма буенча административ җәза билгеләү турында карар;

әлеге Регламентка 4 нче кушымтада каралган форма буенча административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктату турында карар.

Башкару срогы: административ хокук бозулар турында беркетмә төзелгән вакыттан алып унбиш көн эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү турында карар йә административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктату турында карар.

5.30. Административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү турында карарның күчермәсе йә административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктату турында карарның күчермәсе ул кемгә карата чыгарылган, шул физик затка яки физик затның законлы вәкиленә, яки юридик

затның законлы вәкиленә кул куйдыртып тапшырыла йә күрсәтелгән затларга тапшырылу турында хәбәр ителә торган заказлы почта юлламасы белән җибәрелә.

Башкару срогы: административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү турында йә административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктату турында карар чыгарылган көннән алып өч көн эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затка яки индивидуаль эшкуарга тапшырылган яки җибәрелгән административ хокук бозу турында эш буенча административ җәза билгеләү турында карарның күчермәсе йә административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктату турында карарның күчермәсе.

5.31. Административ процедура тәгәлләнгәннән соң, җаваплы башкаручы, документларга план буенча үткәрелгән тикшерүнең нәтиҗәсен теркәп кую максатыннан чыгып, Дәүләт комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә тиешле мәгълүматны Дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштыру турында хезмәт язмасын юллый.

Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертә.

Башкару срогы: мәгълүматны Дәүләт комитеты сайтына урнаштыру - тикшерү акты имзаланган көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча;

тикшерүләрнең бердәм реестрына мәгълүмат кертү - билгеләнгән срокларда.

Гамәл нәтиҗәсе: документларга план буенча үткәрелгән тикшерүнең нәтиҗәләре турында Дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштырылган һәм тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелгән мәгълүмат.

## «ЮРИДИК ЗАТЛАРГА, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРЛАРГА ПЛАН БУЕНЧА КҮЧМӘ ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.32. «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга план буенча күчмә тикшерүләр үткәрү;» административ процедурасын башлап җибәрү өчен тиешле юридик затның, индивидуаль эшкуарның еллык Планга кертелүе һәм юридик затка, индивидуаль эшкуарга план буенча тикшерү үткәрү сроклары җитү, шулай ук документларга тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләрне башкару мөмкин булмаса:

1) эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамәдә булган һәм юридик затның, индивидуаль эшкуарның Дәүләт комитеты карамагындагы башка документларында булган белешмәләрнең тулылыгына һәм дөреслегенә инану;

2) юридик зат, индивидуаль эшкуар эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килү-килмәвен тиешле тикшерү чараларын үткәрмичә генә бәяләү.

«Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга план буенча күчмә тикшерүләр үткәрү;» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.22 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибенә нигезләнеп гамәлгә ашырыла.

5.33. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгеләү, план буенча күчмә тикшерү үткәрү турында боерык

әзерләү, план буенча күчмә тикшерү үткәрү турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга хәбәр итү әлеге Регламентның 5.23 – 5.25 пунктлары нигезендә башкарыла.

5.34. Күчмә тикшерү Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан хезмәт таныклыгын күрсәтүдән, юридик затның җитәкчесен яки башка вазыйфаи затын, индивидуаль эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен күчмә тикшерү билгеләнү турында Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) боерыгы белән һәм күчмә тикшерүне үткәрүче затларның вәкаләтләре, шулай ук күчмә тикшерү үткәрүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, тикшерү чараларының төрләре һәм күләме, экспертларның составы, күчмә тикшерү үткәрү өчен җәлеп ителә торган экспертиза оешмаларының вәкилләре, аны үткәрү сроклары һәм шартлары белән мәҗбүри таныштырудан башлана.

Тикшерелергә тиешле затларның таләбе буенча Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары үзләренең вәкаләтләрен раслау максатларында Дәүләт комитеты турында, шулай ук экспертлар, экспертиза оешмалары турында мәгълүмат бирергә тиеш.

Юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки индивидуаль эшкуарны, аның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары тикшерелергә тиешле затларны тикшерү чараларын үткәрүнең һәм аларны юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашырганда файдаланыла торган объектларда үткәрүнең административ регламентлары белән таныштырырга тиеш.

Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары тикшерү барышында, төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектлары товарларын һәм хезмәт күрсәтүләрен кулланучыларның язма соратуларына нигезләнеп, тиешле эшчәнлек өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан үтәлү-үтәлмәве турында нәтиҗәләр чыгару өчен әһәмиятле булган, әлеге Регламентның 4 бүлегендә китерелгән документларны, шул исәптән язма соратуларны теркәү документларын, аларны карауның үз вакытында башкарылуын һәм тулылыгын, шулай ук карау нәтиҗәләре турындагы хәбәрнамәләр өйрәнелә.

Тикшерүләр үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү буенча түбәндәге чараларны үткәрәләр:

1) элек үткәрелгән тикшерү барышында мәгълүмат ачу стандартларының ачыкланган бозуларның тулысынча бетерелүен тикшерәләр;

2) тикшерелә торган оешманың тикшерү предметын тәшкил иткән мәсьәләләр буенча эшчәнлеген характерлый торган документларны һәм материалларны карыйлар.

Башкару срогы: әлеге Регламентның 2.8 пункты таләпләре нигезендә тикшерүләр үткәрү срогы.

Гамәл нәтиҗәсе: үткәрелгән тикшерү чаралары.

5.35. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү буенча чаралар күрү әлеге Регламентның 5.28 – 5.30 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.36. Җаваплы башкаручы дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, тикшерү үткәрүнең башлану һәм төгәлләнү даталары, аны үткәрү вакыты, тикшерүнең төре, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында белешмәләрне үз эченә алган, шулай ук тикшерүне үткәрүче затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре күрсәтелгән һәм аларның имзалары салынган юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) план буенча үткәрелгән күчмә тикшерү турында язма кертә.

Башкару срогы: турыдан-туры тикшерү төгәлләнгәннән соң.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) план буенча үткәрелгән күчмә тикшерү турында язма.

5.37. Административ процедура төгәлләнгәннән соң җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны Дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштыруны һәм тикшерүләрнең бердәм реестрына әлеге Регламентның 5.31 пункты нигезендә тиешле мәгълүмат кертүне оештыра.

5.38. Индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының урында булмавы аркасында йә юридик зат, индивидуальэшкуар тарафыннан чынбарлыкта эшчәнлекнең гамәлгә ашырылмавына бәйле рәвештә, йә индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавына китергән башка гамәленә (гамәл башкармавына) бәйле рәвештә план буенча урынга барып тикшерү үткәреп булмаса, Дәүләт комитетының вазыйфаи заты, тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавы сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзи. Бу очракта Дәүләт комитеты тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзегән көннән алып өч ай эчендә мондый юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата план буенча урынга барып тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы, бу вакытта план буенча тикшерү план буенча тикшерүләрнең еллык Планына кертелми һәм аның хакында юридик затка, индивидуаль эшкуарга алдан хәбәр ителми.

## «ЮРИДИК ЗАТЛАРНЫҢ, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРЛАРНЫҢ ДОКУМЕНТЛАРЫНА ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.39. «Юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның документларына планнан тыш тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлау өчен әлеге Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез була.

Административ процедура гамәлләрнең түбәндәге тәртибе нигезендә

башкарыла:

1) тикшерү үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү;

2) тикшерүне үткәрү турында боерыкны рәсмиләштерү;

3) тикшерү үткәрелү турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга хәбәр итү;

4) тикшерүне үткәрү;

5) тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү, шул исәптән мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуын бетерү буенча чаралар күрү.

Дәүләт комитеты бүлекләренең үз компетенциясе чикләрендә тикшерү үткәрүче башлыклары юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның документларына тикшерүләр үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларны һәм юридик затның, индивидуаль эшкуарның документларына планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен җаваплы башкаручыны билгелиләр.

Башкару срогы: документларга планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән алып бер эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: документларга планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен билгеләнгән вәкаләтле вазыйфаи затларның һәм җаваплы башкаручының исемлеге.

5.14. Юридик затның, индивидуаль эшкуарның документларына планнан тыш тикшерү үткәрү турында Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) боерыгын әзерләү әлеге Регламентның 5.24 пунктында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Башкару срогы: документларга планнан тыш тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар билгеләнгәннән соң өч эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: Дәүләт комитеты рәисе (рәисе урынбасары) имзалаган юридик затның, индивидуаль эшкуарның документларына планнан тыш тикшерү үткәрү турында боерык.

5.42. Җаваплы башкаручы документларга планнан тыш тикшерү үткәрү турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга мөмкин булган теләсә нинди ысул белән хәбәр итә, шул исәптән квалификацияле көчәйтелгән электрон имза салынган һәм юридик затның, индивидуаль эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән, әгәр мондый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән йә элек Дәүләт комитетына юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан тапшырылган булса, электрон документ рәвешендә хәбәр итә.

Тикшерү үз-үзен җайга сала торган оешманың әгъзасы булган юридик затка, индивидуаль эшкуарга үткәрелгән очракта, җаваплы башкаручы шулай ук үз-үзен җайга сала торган оешмага аның вәкиленең документларга планнан тыш тикшерү үткәрелгәндә катнашу яки булу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында хәбәрнамә юллый.

Гамәл нәтиҗәсе: документларга планнан тыш тикшерү үткәрелү турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга хәбәр итү.

5.43. Юридик зат, индивидуаль эшкуар боерык күчермәсен алган вакыттан 10 эш көне эчендә Дәүләт комитетына документларга планнан тыш тикшерү үткәрелү турында боерыкта күрсәтелгән документларны җибәрергә тиеш.

Күрсәтелгән документлар мөһер белән (булган очракта) һәм тиешенчә

индивидуаль эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, юридик затның җитәкчесе яки башка вазыйфаи заты имзасы белән таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла. Юридик зат, индивидуаль эшкуар соратуда күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә җибәрергә хокуклы.

Дәүләт комитетына тапшырыла торган документлар күчермәләренең, әгәр башкасы Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса, нотариаль таныклануын таләп итү рөхсәт ителми.

Дәүләт комитеты юридик заттан, индивидуаль эшкуардан Дәүләт комитеты тарафыннан башка дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуксыз.

5.44. Юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның доукументларындагы белешмәләрне бәяләү, тапшырылган документларда күрсәтмәләргә карата юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның аңлатмаларын карау әлеге Регламентның 5.27 пунктында каралган тәртиптә башкарыла.

5.45. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү буенча чаралар күрү әлеге Регламентның 5.28 – 5.30 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.46. Административ процедура төгәлләнгәннән соң җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны Дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштыруны һәм тикшерүләрнең бердәм реестрына әлеге Регламентның 5.31 пункты нигезендә тиешле мәгълүмат кертүне оештыра.

## «ЮРИДИК ЗАТЛАРГА, ИНДИВИДУАЛЬ ЭШКУАРЛАРГА ПЛАННАН ТЫШ КҮЧМӘ ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.47. «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасы өчен әлеге Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез була, шулай ук документларга тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләрне башкару мөмкин булмаса:

1) эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәрнамәдә булган һәм юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның Дәүләт комитеты карамагындагы башка документларында булган белешмәләрнең тулылыгына һәм дөреслегенә инану;

2) юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килү-килмәвен тиешле тикшерү чараларын үткәрмичә генә бәяләү.

«Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү» административ процедурасы әлеге Регламентның 5.22 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибенә нигезләнеп гамәлгә ашырыла.

5.48. Дәүләт комитетының үз компетенциясе чикләрендә тикшерү үткәрүче бүлекләре башлыклары юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга планнан тыш

күчмә тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгели.

Планнан тыш күчмә тикшерү үткәргән вакытта экспертлар, экспертиза оешмалары катнашында контроль чараларын үткәрү таләп ителгән очракта, Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) тикшерү үткәрелә торган юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар белән граждан-хокук һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә булмаган һәм тикшерелә торган затларның йогынты ясый алырлык затлары булып тормаган экспертларны, экспертиза оешмаларын җәлеп итә.

Башкару срогы: документларга планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән алып бер эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән вазыйфаи затларның (экспертларның, экспертиза оешмалары вәкилләренең) исемлеге һәм җаваплы башкаручы.

5.49. Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) боерыгын әзерләү әлеге Регламентның 5.24 пунктында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Башкару срогы: планнан тыш күчмә тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар билгеләнгәннән соң өч эш көне эчендә.

Гамәл нәтиҗәсе: Дәүләт комитеты рәисе (рәисе урынбасары) имзалаган юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык.

5.50. Җаваплы башкаручы, үткәрү нигезләре әлеге Регламентның 2.14 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән планнан тыш урынга барып тикшерүдән тыш, планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга теләсә нинди мөмкин булган ысул белән, шул исәптән ныгытылган квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, индивидуаль эшкуарның электрон почта адресына, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән булса, йә элегрәк Дәүләт комитетына юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан тапшырылган булса, электрон документ ярдәмендә яки башка мөмкин булган ысул белән хәбәр итә.

Башкару срогы: тикшерүне үткәрү башланганчы кимендә егерме дүрт сәгать кала.

Гамәл нәтиҗәсе: планнан тыш күчмә тикшерү үткәрелү турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга хәбәр итү.

5.51. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү әлеге Регламентның 5.34 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.52. Тикшерү актын төзү, юридик затка, индивидуаль эшкуарга тикшерү актын тапшыру, тикшерү барышында ачыкланган бозуларның фактларына карата законнарда каралган чаралар күрү әлеге Регламентның 5.28 – 5.30, 5.35 пунктлары нигезендә башкарыла.

5.53. Җаваплы башкаручы дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, тикшерү үткәрүнең башлану һәм тәгәлләнү даталары, аны үткәрү вакыты, тикшерүнең төре,

тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турында белешмәләрне үз эченә алган, шулай ук тикшерүне үткәрүче затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре күрсәтелгән һәм аларның имзалары салынган юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) планнан тыш үткәрелгән күчмә тикшерү турында язма кертә.

Башкару срогы: турыдан-туры тикшерү төгәлләнгәннән соң.

Гамәл нәтиҗәсе: юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) планнан тыш үткәрелгән күчмә тикшерү турында язма.

5.54. Административ процедура төгәлләнгәннән соң җаваплы башкаручы тиешле мәгълүматны Дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштыруны һәм тикшерүләрнең бердәм реестрына әлеге Регламентның 5.31 пункты нигезендә тиешле мәгълүмат кертүне оештыра.

5.55. Индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының урында булмавы аркасында йә юридик зат, индивидуальэшкуар тарафыннан чынбарлыкта эшчәнлекнең гамәлгә ашырылмавына бәйле рәвештә, йә индивидуаль эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавына китергән башка гамәленә (гамәл башкармавына) бәйле рәвештә урынга барып планнан тыш тикшерү үткәреп булмаса, Дәүләт комитетының вазыйфаи заты, тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавы сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзи. Бу очракта Дәүләт комитеты тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзегән көннән алып өч ай эчендә мондый юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата планнан тыш урынга барып тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы, бу вакытта планнан тыш күчмә тикшерү хакында юридик затка, индивидуаль эшкуарга алдан хәбәр ителми.»;

## 6. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН БАШКАРУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ АНЫ ТИКШЕРҮ ФОРМАЛАРЫ

6.1. Дәүләт комитеты вазыйфаи затлар тарафыннан аларның хезмәт бурычларының үтәлешен тикшереп тора, вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт бурычларының тиешенчә үтәлмәү очракларының исәбен алып бара, тиешле хезмәт урынында тикшерүләр үткәрә һәм мондый вазыйфаи затларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрә.

6.2. Әлеге Регламентның үтәлешен тикшереп торуны Дәүләт комитеты рәисе гамәлгә ашыра.

6.3. Дәүләт функцияләренең әлеге Регламент нигезендә үтәлү срокларының, гамәлләр эзлеклелегенең үтәлүенә, Дәүләт комитеты вазыйфаи затлары тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп торуны компетенциясенә дәүләт функциясен әашкару кергән Дәүләт комитеты рәисе урынбасары һәм Дәүләт

комитеты бүлекләре башлыклары гамәлгә ашыра.

6.4. Дәүләт функциясен башкаруның тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү план буенча һәм планнан тыш булырга мөмкин.

План буенча тикшерүләр Дәүләт комитетының агымдагы елга расланган эш планы нигезендә үткәрелә.

Планнан тыш тикшерүләр Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының дәүләт функциясен башкару барышында кабул ителгән яки башкарылган карарларына яки гамәлләренә (гамәл башкармауларына) гражданнарның шикаятьләренә нигезләнеп оештырыла һәм үткәрелә.

Тикшерүләр мәнфәгатьле затларның хокуклары, Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл башкармауларына) яки карарларына гражданнарның шикаятьләрен карауда, алар буенча карарлар кабул итүдә һәм аларга җаваплар әзерләүдә таләпләр бозылу очракларын ачыклау һәм бетерү максатыннан үткәрелә.

Дәүләт комитеты вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламент һәм дәүләт функциясен башкаруга таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлар нигезләмәләренең үтәлешенә тикшерүләр үткәрү ешлыгы Дәүләт комитетының агымдагы елга расланган эш планы нигезендә билгеләнә.

6.5. Әлеге Регламентның үтәлешенә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан контроль Дәүләт комитетына мөрәҗәгатьләр юллау юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында башкарылган (кабул ителгән) гамәлләргә (гамәлләр башкармауга) һәм карарларга дәүләт хакимиятенең югарырак органнарына шикаять белдерү юлы белән башкарыла.

6.6. Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгән, тикшерү үткәргәндә хокукка каршы гамәлләр башкарган (гамәлләр башкармаган) очракта Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

Гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында Дәүләт комитеты хокуклары һәм (яки) мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, индивидуаль эшкуарга мондый чаралар күрелгән көннән алып ун көн эчендә язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

## 7. ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫНЫҢ, ШУЛАЙ УК АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ КАРАРЛАРЫНА ЯКИ ГАМӘЛЛӘРЕНӘ (ГАМӘЛЛӘР БАШКАРМАВЫНА) СУДКА КАДӘР (СУДТАН ТЫШ) ШИКАЯТЬ БИРҮ ТӘРТИБЕ

7.1. Юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар Дәүләт комитетының, шулай ук аның вазыйфаи затларының тикшерү үткәрелгәндәге гамәлләренә (гамәлләр башкармавына) һәм алар кабул иткән карарга судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирергә хокуклы. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белән мөрәҗәгать итү язма рәвештә рәсмиләштерелергә һәм Дәүләт комитеты исеменә җибәрелергә тиеш.

7.2. Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәлләр башкармавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы

Дәүләт комитеты  вазыйфаи затларының дәүләт функциясен башкару барышында кабул ителгән яки башкарылган карарлары яки гамәллләре (гамәлләр башкармавы) була.

7.3. Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының гамәллләренә (гамәлләр башкармавына) шикаять Дәүләт комитеты рәисенә җибәрелә ала. Дәүләт комитетының һәм Дәүләт комитеты рәисенең гамәленә (гамәл башкармавына), карарына шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелергә мөмкин.

7.4. Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәлләр башкармавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен Дәүләт комитетына гариза бирүчедән шикаять алыну нигез була. Судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне караудан баш тарту яки аны карауны туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

7.5. Әгәр язма шикаятьтә шикаять юллаган гражданның фамилиясе (юридик зат исеме) яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (электрон почта адресы) күрсәтелмәгән булса, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән шикаятьтә әзерләнә торган, башкарыла торган яки башкарылган хокукка каршы гамәлләр турында, шулай ук аны әзерләгән, башкара торган яки башкарган зат турында белешмәләр булса, шикаять дәүләт органына аның компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш.

Әгәр язма шикаять текстын укып булмаса, шикаятькә җавап бирелми, бу хакта шикаять теркәлгән көннән лаып җиде көн эчендә шикаять юллаучыга, әгәр аның фамилиясен (юридик зат исемен) һәм почта адресын укып булса, хәбәр ителә.

Әгәр язма шикаятьнең тексты шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка аларның компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә шикаятьне юллаган гариза бирүчегә хәбәр ителә.

Әгәр гариза бирүченең язма шикаятендә аңа элек җибәрелгән шикаятьләренең асылына бәйле рәвештә берничә тапкыр язма җавап җибәрелгән булса,  һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр һәм шартлар китерелмәсә,  Дәүләт комитеты рәисе, Дәүләт комитетының вазыйфаи заты йә моңа вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи заты чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча гариза бирүче белән язышуны туктату турында  карар кабул итәргә хокуклы, тик бу очракта күрсәтелгән шикаять һәм элек юлланган шикаятьләр берүк күзәтчелек органына һәм берүк вазыйфаи затка юлланган булырга тиеш, Әлеге карар турында шикаять юллаган гариза бирүчегә хәбәр ителә.

Әгәр Дәүләт комитетына яки вазыйфаи затка 59-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 4 өлеше нигезендә җавабы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштырылган сорауны үз эченә алган язма шикаять кергән очракта, шикаять юллаган гражданга шикаятьне теркәгән көнән алып җиде көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының шикаятьтә куелган сорауга

җавап урнаштырылган рәми сайтының электрон адресы хәбәр ителә, бу очракта суд карарына шикаять белдерүне үз эченә алган шикаять кире кайтарылмый.

Әгәр шикаятьтә куелган сорауның асылы буенча җавапны дәүләт серен яки федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән мәгълүматны фаш итмичә генә бирү мөмкин булмаса, шикаять юллаган гариза бирүчегә, күрсәтелгән мәгълүматларны фаш итәргә ярамаганга күрә, анда куелган сорауның асылы буенча җавап бирүнең мөмкин булмавы турында хәбәр ителә.

Дәүләт комитеты цензурасыз йә вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә карата хурлау сүзләре, янаулар булган язма шикаять алган очракта, шикаятьне анда куелган сорауларның асылы буенча җавапсыз калдырырга һәм шикаять юллаган гариза бирүчегә бу хокуктан явыз ният белән файдалануның ярамавы турында хәбәр итәргә хокуклы.

Суд карарына шикаять белдерелгән шикаять теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә шикаять юллаган гариза бирүчегә кире кайтарыла, анда әлеге суд карарына шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Шикаятьтә куелган сорауларның асылы буенча җавап бирелә алмаган сәбәпләр алга таба бетерелсә, гариза бирүче Дәүләт комитетына кабат  шикаять юллый ала.

7.6. Юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алырга хокуклы. Мондый мәгълүматны һәм документларны алу өчен юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар Дәүләт комитетына язма рәвештә тиешле сорату җибәрергә тиеш. Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары сорала торган белешмәләрне һәм документларны сорату теркәлгән көннән алып 30 көн эчендә бирергә тиеш.

7.7. Судка кадәрге (судтан тыш) шикаятьләр Дәүләт комитеты тарафыннан алар теркәлгән көннән алып 30 көн эчендә карала.

7.8. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

1) тикшерүләр үткәргәндә вазыйфаи затның гамәлләренә (гамәлләр башкармавына) һәм ул кабул иткән карарларга судка кадәрге (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндерү, аерым алганда:

а) хезмәт урынында тикшерү барышында аның тарафыннан хезмәт бурычларының тиешенчә үтәлмәве фактлары ачыкланган очракта, вазыйфаи затка (вазыйфаи затларга) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрү;

б) хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында мондый чаралар крелгән көннән алып ун көн эчендә язма рәвештә хәбәр итү;

2) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру барышында кабул ителгән (башкарылган) гамәлләргә (гамәлләр башкармауга) һәм караларга судка кадәрге (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндермичә калдыру, бу хакта юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга язма рәвештә мондый карарның чәбәпләре аңлатылган нигезләү белән хәбәр ителә.

Шикаятьләрне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән аңлатмалар бирелгән

җавап язма рәвештә гариза бирүчегә җибәрелә һәм, гариза бирүче теләк белдергән очракта, электрон рәвештә әлеге Административ регламентның 7.7 пунктында күрсәтелгән срокта юллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының дәүләт тарафыннан
җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә
газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы
табигый монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм
ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән
тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары,
каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча
региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән
эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне,
салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны
чыгаруны башкаручы оешмалар тарафыннан
мәгълүмат ачу стандартларының үтәлеше өлешендә төбәк
дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына
1 нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

КҮРСӘТМӘ № _____
МӘГЪЛҮМАТ АЧУ СТАНДАРТЛАРЫНЫҢ АЧЫКЛАНГАН БОЗЫЛУЫН ТУКТАТУ (БЕТЕРҮ) ТУРЫНДА

Казан ш. «___»_______, 20___ел

Мин, ___________________, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе (рәисе вазыйфаларын башкаручы)
(Ф.И.А.и.)
20___ елның _________, _________ номерлы боерыгы нигезендә ________________________________________________________________________________________________________
_____________ карата үткәрелгән тикшерү материалларын карап,
(индивидуаль эшкуарның Ф.И.А.и. яки юридик затның исеме)

КҮРСӘТМӘ БИРӘМ
________________________________________________________________________________
(күрсәтмә бирелә торган индивидуаль эшкуарның Ф.И.А.и. яки юридик затның исеме)

| т/б № | Күрсәтмәнең эчтәлеге <*> | Башкару срогы: | Күрсәтмә бирү өчен нигез <**> |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |
| | | | |

Күрсәтмәгә законда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин. Шикаять бирү әлеге күрсәтмәнең үтәлешен туктатып тормый.

Күрсәтмә бирелгән зат әлеге күрсәтмәнең үтәлеше турында мәгълүматны Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына аның үтәлү срогы беткән датадан алып ______ көннән дә соңга калмыйча юлларга тиеш.

Рәис ______________________ ________________________________________
(имза) (Ф.И.А.и.)

Күрсәтмә алынды

_____________________________________ _____________________________________________

(Тикшерелә торган индивидуаль эшкуарның яки юридик затның вәкаләтле вәкиленең Ф.И. А.и.)

--------------------------------

<*> Тикшерү үткәрелгән зат башкарырга тиешле төгәл чаралар күрсәтелә.

<**> Күрсәтмә бирелә торган бурычны күз алдында тоткан норматив хокукый актка сылтама ясала.

.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар)
өлкәсендә газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы
табигый монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм
ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән
тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары,
каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча
региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән
эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне,
салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны
чыгаруны башкаручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу
стандартларының үтәлеше өлешендә төбәк
дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына
2 нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

Административ хокук бозу турында
БЕРКЕТМӘ №__________

«__» __________, 20__ ел ___________________
(язылу урыны)

________________________________________________________________________________
(беркетмә язган затның вазыйфасы, Ф.И.А.и.)

________________________________________________________________________________
____ башкарганда
(хокук бозуның җитәрлек мәгълүматларын табу шартлары, турыдан-туры табу шартлары, материаллар, хәбәрләр, гаризалар алыну күрсәтелә)

______________________________________________________________________ катнашында
(гражданның, вазыйфаи затның, юридик затның законлы вәкиленең Ф.И. А.и.)

БИЛГЕЛӘДЕ:

________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(административ хокук бозуны кылу урыны, вакыты һәм вакыйгалары турында мәгълүмат, әлеге административ хокук бозу өчен административ җаваплылык каралган КоАП РФ статьясы күрсәтелә)

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, КоАП РФ 28.1 - 28.3 статьяларына нигезләнеп, ______________________________________________________
(беркетмә язган затның вазыйфасы, Ф.И. А.и) административ хокук бозу турында әлеге беркетмәсне төзеде.

Административ хокук бозу турында эш кузгатылган зат турында белешмәләр:

________________________________________________________________________________
(юридик зат: тулы исеме, юридик адресы, ОГРН, ИНН; граждан, вазыйфаи зат: Ф.И.А.и., туу датасы, паспорт белешмәләре, теркәлү урыны)

КоАП РФ 25.1 статьясындагы 1 өлеше нигезендә административ хокук бозу турында эш буенча эш башкарыла торган зат барлык материаллар белән танышырга, аңлатмалар бирергә, дәлилләр китерергә, гозырнамәләр һәм кире кагулар белдерергә, яклаучының юридик ярдәменнән, шулай ук КоАП РФ нигезендә башка процессуаль хокуклардан файдаланырга хокуклы.

Административ хокук бозу турында эш кузгатылган затның (вәкиленең) аңлатмасы:

________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________.

Хокуклар һәм бурычлар аңлатылды ____________ «__» ________ , 20__ ел
Беркетмә белән танышып чыктым ____________ «__» _________, 20__ ел
Беркетмәнең күчермәсен алдым ____________ «__» ________, 20__ ел

(беркетмә язган затның вазыйфасы, Ф.И.А.и.) (имза)

Беркетмәгә имза куюдан яки аны алудан баш тартылган очракта, бу хакта тамга куела

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар)
өлкәсендә газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы
табигый монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм
ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән
тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары,
каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча
региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән
эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне,
салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык
суны чыгаруны башкаручы оешмалар тарафыннан
мәгълүмат ачу стандартларының үтәлеше өлешендә
төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына
3 нче кушымта

Административ хокук бозу турында эш буенча
КАРАР

_______________________________________________ «__» _________, 20__ ел
(каралу урыны)

_____________________________________________________________________________,
(карар чыгарган затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары)

_______ номерлы административ хокук бозу турында эш материалларын карап, ул _________________________________________________________________ карата кузгатылган,
(гражданның, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затның исеме)

_____________________________________________________________________________

__катнашында
(гражданның, вазыйфаи затның, юридик затның законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

БИЛГЕЛӘДЕ:

_____________________________________________________________________________
(административ хокук бозу турында эш караганда билгеләнгән шартлар,

_____________________________________________________________________________
законнарның бозылган нормалары бәян ителә)

_____________________________________________________________________________.

Бәян ителгәннәргә нигезләнеп, КоАП РФ _____________________ статьяларына таянып,

КАРАР БИРДЕМ:

_____________________________________________________________________________
(гражданның, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затның исеме)

КоАП РФ _____ статьясының ______ өлеше буенча административ җаваплылыкка тартырга һәм түбәндәге күләмдә административ штраф рәвешендә җәза бирергә:

_______________________________________________ ________________________
(карар чыгарган затның вазыйфасы, Ф.И.А.и.) (имза)

Административ хокук бозу турында эш буенча чыгарылган әлеге карарга шикаять карар күчермәсе тапшырылган яки алынган көннән алып ун тәүлек эчендә бирелергә мөмкин (КоАП РФ 30.3 статьясындагы 1 өлеше)

КоАП РФ 31.1 статьясындагы 1 өлеше нигезендә административ хокук бозу турында эш буенча карар административ хокук бозу турында эш буенча карарга шикаять бирү өчен билгеләнгән срок беткәннән соң, әгәр күрсәтелгән карарга шикаять белдерелмәгән яки протест белдерелмәгән булса, законлыкөченә керә. 30.1 статьясының 1 өлешендә каралганча, вазыйфаи зат тарафыннан чыгарылган административ хокук бозу турында эш буенча карарга югарырыак органга, югарырак вазыйфаи затка йә эш каралу урыны буенча район судына шикаять бирелергә мөмкин.

КоАП РФ 32.2 статьясындагы 1 өлеше нигезендә административ штраф, административ штраф салу турында карар законы көченә кергән көннән йә КоАП РФ 31.5 статьясында каралган кичектереп тору срогы яки өлешләп түләү срогы беткән көннән алтмыш көннән дә соңга калмыйча, административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан түләнергә тиеш.

Административ штраф суммасы түбәндәге реквизитлар буенча күчерелергә тиеш: ___________________________________________________________________________.

КоАП РФ 32.2 статьясындагы 5 өлешендә каралганча, административ штрафның түләнүен раслый торган документ булмаган очракта, КоАП РФ 32.2 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән сроктан соң алтмыш көн узгач, карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тиешле материалларны, административ штраф суммасын федераль законнарда каралган тәртиптә түләттерү өчен, башкаручы суд приставына җибәрәләр. Моннан тыш, административ штраф билгеләнгән вакытта түләнмәгән очракта, гаепле зат КоАП РФ 20.25 статьясындагы 1 өлеше буенча административ җаваплылыкка тартыла, аның буенча түләнмәгән административ штрафның икеләтелгән күләмендә административ штраф салу каралган.

Карар белән таныштым, күчермәсен алдым ________________________________________
___________________________________________________________________________

«__» __________, 20__ ел

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар)
өлкәсендә газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы
табигый монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм
ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән
тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары,
каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча
региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән
эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне,
салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык
суны чыгаруны башкаручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу
стандартларының үтәлеше өлешендә төбәк
дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына
4 нче кушымта

Административ хокук бозу турында эш буенча
эш башкаруны туктату турында
КАРАР

________________________________________ «__» __________, 20__ ел
(каралу урыны)

____________________________________________________________,
(карар чыгарган затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары)

_______ номерлы административ хокук бозу турында эш материалларын карап, ул ____________________________________________ карата кузгатылган,
(гражданның, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затның исеме)

____________________________________________ катнашында
(гражданның, вазыйфаи затның, юридик затның законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

БИЛГЕЛӘДЕ:

____________________________________________________________
(административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны таләп итмәгән билгеләнгән шартлар күрсәтелә)

____________________________________________________________

____________________________________________________________.

Бәян ителгәннәргә нигезләнеп, КоАП РФ ______________________ статьяларына таянып,

КАРАР БИРДЕМ:

____________________________________________ карата кузгатылган административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктатырга,
(гражданның, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затның исеме)
чөнки

_____________________________________________________________
_.
(административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны таләп итмәгән шартлар күрсәтелә).

________________________________________ ___________________________
(карар чыгарган затның вазыйфасы, Ф.И.А.и.) (имза)

Административ хокук бозу турында эш буенча чыгарылган әлеге карарга шикаять карар күчермәсе тапшырылган яки алынган көннән алып ун тәүлек эчендә бирелергә мөмкин (КоАП РФ 30.3 статьясындагы 1 өлеше)

Карар белән таныштым, күчермәсен алдым ______________________________________

____________________________________________________________
(юридик зат вәкиленең фамилиясе, инициаллары, вазыйфасы, имзасы, дата)

«__» _________, 20__ ел


Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар)
өлкәсендә газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы
табигый монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм
ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән
тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары,
каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча
региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән
эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне,
салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык
суны чыгаруны башкаручы оешмалар тарафыннан
мәгълүмат ачу стандартларының үтәлеше өлешендә төбәк
дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына
5 нче кушымта


**Системалы күзәтү башкарганда һәм анализ ясаганда**
**гамәлләрнең эзлеклелеге блок-схемасы**



Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар)
өлкәсендә газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы табигый
монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм ваклап сату
базарлары субъектлары, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар,
җылылык челтәрләре оешмалары, каты коммуналь калдыклар
белән эш итү буенча региональ операторлар, каты коммуналь
калдыклар белән эш итү буенча операторлар, кайнар су белән
тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки)
ташландык суны чыгаруны башкаручы оешмалар тарафыннан
мәгълүмат ачу стандартларының үтәлеше өлешендә төбәк
дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына
6 нчы кушымта

**План буенча һәм планнан тыш тикшерүләр үткәргәндә гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**




Тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерләү һәм аны рәис (рәис урынбасары) тарафыннан имзалау
План буенча тикшерү, планнан тыш тикшерү үткәрелү турында юридик затка, индивидуаль эшкуарга хәбәр итү.
Документларга тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү рәвешендә план әуенча һәм планнан тыш тикшерү үткәрү
Мәгълүмат ачу стандартлары бозылмаганда
Тикшерү актын төзү
Мәгълүмат ачу стандартлары бозылу ачыкланганда
Тикшерү актын төзү
Хокук бозучы исеменә мәгълүмат ачу стандартларының бозылуын бетерү турында күрсәтмә чыгару
КоАП РФ нигезендә административ хокук бозу турында эш кузгату
Күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп тору, таләп бозуларны бетерелүенә
КоАП РФ нигезендә административ эш башкару

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар)
өлкәсендә газ бүлү челтәрләре буенча газ кууны башкаручы
табигый монополияләр, электр энергиясен күмәрләп һәм
ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән
тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары,
каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча
региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән
эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне,
салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык
суны чыгаруны башкаручы оешмалар тарафыннан
мәгълүмат ачу стандартларының үтәлеше өлешендә төбәк
дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча
дәүләт функциясен башкаруның административ регламентына
7 нче кушымта

Раслыйм
Рәис урынбасары
____________________________
(ФИАи, имза)
«___» _____________, 20__ел

Мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүенә контрольне системалы күзәтү һәм анализ рәвешендә гамәлгә ашыру өчен юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның исемлеге

| № | Контроль субъекты | ИНН | Контроль субъектының эшчәнлек өлкәсе | Контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затның ФИАи |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |

Бүлек башлыгы:____________________________ «_____» __________, 20____ел
(ФИАи, имза)